| **Гыйнвар**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Чәй табыны әзерлибез.<br><br>*Сүзлек:*<br>чынаяк | **Уен ситуациясе «Чәй табыны әзерлибез».**<br>*Аудио (34 нче кисәк)*<br>*(Для гостей мы поставили на стол ложку — кашык, тарелку — тәлинкә. А сегодня поставим чашку — чынаяк. Өстәлдә төрле зурлыктагы уенчык савыт-сабалар: тәлинкә, кашык, чынаяк. «Слушай!» — «Тыңла!»*<br>*Тәрбияче чынаяк рәсеме яки уенчыгы күрсәтә.* ***Чынаяк*** *сүзе яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.)*<br>**Сүзле уен «Тыңла, күрсәт, кабатла!»**<br>*Аудио (35–36 нчы кисәк) «Слушай, покажи, повтори!» — «Тыңла, күрсәт, кабатла!»*<br>*(Балалар таратма рәсем яки уенчык чынаяк күрсәтә, кабатлый.)*<br>**Сүзле уен «Төсле чынаяк».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Балалар түгәрәктә. Тәрбияче балаларга, төрле төстәге уенчык чынаякны яки рәсемне биреп, сүзтезмәне әйтә: Мә кызыл чынаяк. Мә сары чынаяк. Мә яшел чынаяк.)*<br>**Уен ситуациясе «Курчак, Алиягә чәй табыны әзерләргә булыш».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Өстәлдә төрле зурлыктагы төсле чынаяклар, тәлинкәләр, кашыклар. Балалар тәрбиячедән савыт-сабаны сорап алалар, Алиягә бирәләр.)* | Һәр балага җитәрлек төрле зурлыктагы һәм төстәге (сары, кызыл, яшел, зәңгәр) савыт-саба: тәлинкә, кашык, чынаяк муляжлары, рәсемнәре. |
| **Гыйнвар**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Өч аю.<br><br>*Сүзлек:*<br>тәлинкә<br>кашык<br>чынаяк | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Һәр балага җитәрлек таратма рәсемнәр: тәлинкә, кашык,чынаяк. Аудиоязма 34 |
| | | **Сүзле уен «Тыңла, күрсәт, кабатла».** *Аудио (34 нче кисәк)*<br>**Татар халык уены «Чүлмәк сатыш».** *(Сан, төсләрне ныгыту.)*<br>**Анимацион сюжет карау «Өч аю».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (147 с.).<br>Курчак театры атрибутлары.<br>Р.Ш. Халикова «Раушан көзге» хрестоматиясе (95 б.).<br>К.В. Закирова «Балачак аланы» (106 б.). |
| | | **Уку Р.Батулла «Медвежонок Аппас».** Хрестоматия «На поляне детства», 12 с.<br>**Уку Б.Рәхмәт «Аш вакыты».**<br>**Уку Р.Батулла «Аю Әппәс».**<br>**«Три медведя».** *(Кечкенәләр төркеменә тәкъдим итәргә мөмкин. Курчак театры.)* | |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Гыйнвар<br>IV атна<br>4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Төсле чынаяклар.<br><br>*Сүзлек:*<br>зәңгәр | **Сүзле уен «Зәңгәр чынаяк».** *Аудио (37 нче кисәк)*<br>(Тәрбияче: Посмотрите, какая красивая синяя чашка — зәңгәр чынаяк. Мә зәңгәр чынаяк.)<br>**Сүзле уен «Төсле чынаяк».** *(Балалар түгәрәктә. Тәрбияче балаларга, төрле төстәге уенчык чынаякны яки рәсемне биреп, сүзтезмәне әйтә. Балалар тәрбияче үрнәгендә савыт-сабаны бер-берсенә биреп әйтәләр.)*<br>**Сюжетлы-рольле уен «Савыт-саба кибете».** *(Кибеттә төрле төстәге уенчык тәлинкә, кашык, чынаяклар. Акбай сатучы ролендә.)*<br>**Дәфтәрдә эш. 10 нчы бирем «Найди чайную пару».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.)* | Кызыл, сары, яшел төстәге уенчык кашыклар, тәлинкәләр, чынаяклар яки рәсемнәр.<br>Аудиоязма 37.<br>Эш дәфтәре.<br>Интерактив такта. |
| **Гыйнвар<br>IV атна<br>4.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Чисталыкта — матурлык.<br><br>*Сүзлек:*<br>зәңгәр | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Сүзле уен «Ватык телефон», «Тыңла, күрсәт, кабатла».**<br>**Хәрәкәтле уен «Машина, тукта!»**<br>**Анимацион сюжет «Чисталыкта — матурлык».** | Һәр балага җитәрлек таратма рәсемнәр: тәлинкә, кашык, чынаяк.<br>Анимацион сюжет (36 тема). |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Уку Р.Валеева, Р.Кутуй «Весёлый светофор».** *(Шигырьне күрсәтмә рәсемнәр ярдәмендә уку.)*<br>**Фетрдан театр «Чисталыкта — матурлык».** | К.В. Закирова.<br>«На поляне детства» (154 с.).<br>Күрсәтмә рәсемнәр.<br>Фетр театры атрибутлары. |
| **Февраль<br>I атна<br>1.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Туган көнгә яңа киемнәр.<br><br>*Сүзлек:*<br>күлмәк | **Уен ситуациясе «Яңа күлмәк».** *(Тартмада яңа киемнәр: төрле төстәге футболка, сарафан, күлмәкләр. Тәрбияче әни ролендә. Әни кибеттән яңа киемнәр алып кайта. «Күлмәк» сүзе яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.)*<br>Әни: Бу нәрсә?<br>Балалар: Футболка.<br>Әни: Бу нәрсә?<br>Балалар: Сарафан.<br>Әни: Это платье. — Бу күлмәк.<br>**Сүзле уен «Төсле күлмәкләр».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Тартмада төрле төстәге күлмәкләр.)*<br>**Уен «Ватык телефон».** *(«Яшел күлмәк», «матур күлмәк», «чиста күлмәк» сүзтезмәләрен әйтеп уйнала.)*<br>**Дидактик уен «Нәрсә юк?»** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Күлмәк, футболка, сарафан рәсемнәрен кулланып.)* | Тартмада төрле төстәге футболкалар, күлмәкләр, сарафаннар.<br>Интерактив такта. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Февраль**<br>**I атна**<br>**1.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Киемнәр кибете.<br><br>*Сүзлек:*<br>күлмәк<br>чалбар | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Һәр балага җитәрлек таратма рәсемнәр: футболкалар, күлмәкләр, сарафаннар, чалбарлар. |
| | | **Сюжетлы-рольле уен «Киемнәр кибете».**<br>**Аудио тыңлау, кушылып җырлау** *(38 нче кисәк).*<br>**Хәрәкәтле уен «Командир».**<br>**Анимацион сюжет «Киемнәр кибетендә».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (14, 38, 234, 194 с.).<br>«Балачак аланы» (38 с.).<br>Маскалар. Ковробук. |
| | | **Чтение М. Джалиль «Петушок» («Әтәч»), «Мой пёс» («Маэмай»), «Кукушка» («Күке»).** *(Рольләргә бүлеп уйнап карау.)* Хрестоматия «На поляне детства», 14, 194, 234 с. «Балачак аланы» хрестоматиясе, 38, 46 б. «Иң матур сүз» хрестоматиясе, 85 б.<br>**«Кибеткә бардым, күлмәк, чалбар алдым».** *(Ковробукта кибет уены.)* | |
| **Февраль**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Курчакны киендер.<br><br>*Сүзлек:*<br>чалбар | **Уен ситуациясе «Яңа чалбар».** *(Тартмада яңа киемнәр: төрле төстәге футболка, сарафан, күлмәк, чалбарлар. Тәрбияче эти ролендә. Эти кибеттән яңа киемнәр алып кайта.* ***Чалбар*** *сүзе яңа сүз бирү алымнарын кулланып өйрәтелә.)*<br>Эти: Бу нәрсә?<br>Балалар: Футболка.<br>Эти: Бу нәрсә?<br>Балалар: Күлмәк.<br>Эти: Это брюки. — Бу чалбар.<br>**Сүзле уен «Төсле чалбарлар».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Тартмада төрле төстәге чалбарлар.)*<br>**Уен «Ватык телефон».** *(«Яшел чалбар», «матур чалбар», «чиста чалбар» сүзтезмәләрен әйтеп уйнала.)*<br>**Дидактик уен «Курчакны киендер».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Балаларда кәгазьдән ясалган малай һәм кыз курчаклары. Тәрбиячедә курчак киемнәре. Бала, төсен әйтеп, киемнәрне сорап ала.)*<br>**Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.**<br>**Җырлы-биюле уен «Матур».** *Аудио (38 нче кисәк) (Балалар парлашып түгәрәккә басалар. Бер-берсенең киемнәрен күрсәтеп җырлыйлар.)*<br>**Дәфтәрдә эш. 11 нче бирем «Раскрась одежду».** | Тартмада төрле төстәге футболкалар, күлмәкләр, сарафаннар, чалбарлар.<br>Кәгазьдән ясалган кыз, малай курчаклары һәм киемнәре.<br>Эш дәфтәре.<br>Интерактив такта. |
| **Февраль**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Без киенәбез. | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Киемнәр: күлмәк, чалбар, сарафан, футболка.<br>Дәфтәрдә эш.<br>Интерактив такта. |
| | | **Сюжетлы-рольле уен «Киемнәр кибете».** *Аудио (39 нчы кисәк)*<br>**Рус халык уены «Волк во рву».**<br>**Дәфтәрдә эш 11 нче бирем «Раскрась одежду (ИКТ-уен).** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *Сүзлек:*<br>күлмәк<br>чалбар<br>ки<br>сал | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Уку Р.Валеева «Тюбетейка и калфак».** Хрестоматия «На поляне детства», 65 с.<br>**Уку Р.Вәлиева «Кәләпүшем, кәләпүш».** «Балачак аланы» хрестоматиясе, 498 б.<br>**Өстәл театры «Киемнәр кибетендә».** | К.В. Закирова «На поляне детства» (65 с.).<br>«Балачак аланы» (274, 498 б.).<br>Өстәл театры атрибутлары. |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Февраль**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Киенергә ярдәм ит.<br><br>*Сүзлек:*<br>ки | **Уен ситуациясе «Курчакларны киендер».** *Аудио (39 нчы кисәк)*<br>*(Тәрбияче курчак күлмәге, чалбары күрсәтә.)*<br>Тәрбияче: Әйдәгез, курчакны киендерәбез.<br>— Кукла, надень платье. — Курчак, күлмәк ки.<br>*(Тәрбияче кыз курчакка күлмәк кидерә.)*<br>— Курчак, чалбар ки.<br>*(Тәрбияче малай курчакка чалбар кидерә. Аудиоязманы тыңлау, күрсәтмә кәгазь курчакларны киендерү.)*<br>**Дидактик уен «Курчакны киендер».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Балаларда кәгазьдән ясалган кыз һәм малай курчаклары, киемнәр: күлмәк, чалбар, сарафан, футболка. Балалар, бер-берсеннән кием сорап алып, курчакларны киендерәләр.)*<br>**Дәфтәрдә эш. 12 нче бирем «Предложи новый наряд».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.)* | Кәгазьдән ясалган таратма һәм күрсәтмә кыз, малай курчаклары.<br>Уенчык кыз, малай курчаклары.<br>Киемнәр: күлмәк, чалбар, сарафан, футболка.<br>Дәфтәрдә эш.<br>Интерактив такта. |
| **Февраль**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Курчакларга булышабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>күлмәк<br>чалбар<br>ки<br>сал | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Уен ситуациясе «Курчакларга булыш».** *Аудио (39 нчы кисәк)*<br>**Дидактик уен «Курчакны чишендер, киендер».**<br>**Хәрәкәтле уен «Тупны бир — татарча әйт».**<br>**Уен ситуациясе «Курчакны йоклат».**<br>**Аудиоязма «Бишек җыры»** *(43 нче кисәк).* | Уенчык кыз, малай курчаклары.<br>Аудиоязма №39, 43. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Мини-концерт «Минем өем», «Уйный-уйный үсәбез».** *(Кечкенәләр төркеме өчен тәкъдим итәргә мөмкин.)*<br>**Театральләштерелгән уен ситуациясе «Күлмәк, чалбар алабыз, без кунакка барабыз».**<br>**Аз хәрәкәтле уен «Ак димә, кара димә».**<br>**Прослушивание песни «Эх, пляшут наши сапожки».** | К.В. Закирова «Балачак аланы» (135, 138–139 б.). Концерт өчен атрибутлар.<br>К.В. Закирова «Уйный-уйный үсәбез» (91 б.)<br>Диск «Бииләр итек-читекләр». Трэк 1. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Февраль**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Алия йокларга җыена.<br><br>*Сүзлек:*<br>сал<br>йокла | **Уен ситуациясе «Курчакларга булыш».**<br>*Куклам пора спать. Поможем снять платье и брюки. Тәрбияче курчакларның күлмәген, чалбарын салдыра. Курчакларны йокларга яткыра һәм әйтә: «Кукла, спи». — «Курчак, йокла».) Аудио (40 нчы кисәк)*<br>**Аудиоязманы тыңлау. «Слушай!» — «Тыңла!»** *Аудио (41 нче кисәк)*<br>**Дидактик уен «Курчакны чишендер».** *Аудио (42 нче кисәк) «Слушай, повтори, выполни!» — «Тыңла, кабатла, үтә!»*<br>*(Һәр балада таратма кәгазь курчаклар. Балалар биремне тыңлый, кабатлый, үти.)*<br>**Уен ситуациясе «Курчакны йоклат».** *(Һәр балада курчаклар. Балалар курчакларны чишендереп йокларга яткыралар.)*<br>Оля: Курчак, күлмәк сал. Йокла.<br>Коля: Курчак, чалбар сал. Йокла.<br>*(«Бишек җыры» көенә курчакларны тирбәтеп йоклаталар.)*<br>— Курчак, йокла.<br>**Аудиоязма «Бишек җыры».** *Аудио (43 нче кисәк)* | Күрсәтмә кәгазь курчаклар, күлмәкләр, чалбарлар.<br>Уенчык кыз, малай курчаклары.<br>Балалар санынча кәгазь курчаклар, күлмәкләр, чалбарлар.<br>Аудиоязма 40-42. |
| **Февраль**<br>**IV атна**<br>**4.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Кибеттә.<br><br>*Сүзлек:*<br>күлмәк<br>чалбар<br>ки<br>сал<br>нәрсә кирәк? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Сюжетлы-рольле уен «Киемнәр кибете».**<br>**Җырлы-биюле уен «Матур».** *Аудио (38 нче кисәк)*<br>**Эстафета уены «Көчлеләр, җитезләр».**<br>**Дәфтәрдә эш. 12 нче бирем «Предложи новый наряд» (ИКТ-уен).** | Төрле төстәге күлмәкләр.<br>Аудио №38.<br>Эстафета уены өчен атрибутлар.<br>Интерактив такта.<br>Эш дәфтәре. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br><br>**Уку К.Булатова «Солдатлар».**<br>**Уку Р.Миннуллин «Стою на посту».** Хрестоматия «На поляне детства», 68 с.<br>**Җыр «Мин әтине яратам».** *(Тыңлау, аудиоязмага кушылып җырлау.)*<br>**Анимацион сюжет карау «Киемнәр кибетендә».**<br>**Уку Хәйдәр «Керпе туны».** | К.В. Закирова «На поляне детства» (68 с.).<br>К.В. Закирова «Иң матур сүз» (251 б.).<br>К.В. Закирова «Балачак аланы» (102 б.).<br>«Туган телдә сөйләшәбез» методик комплектына өстәмә. (Аудио №30–31.)<br>Анимацион сюжет (39 тема). |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Март**<br>**I атна**<br>**1.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Хәерле көн.<br><br>*Сүзлек:*<br>бит<br>кул<br>хәерле көн | **Уен ситуациясе «Хәерле көн телә».** *(Кукла проснулась. Скажем ей: «Добрый день!» — «Хәерле көн!» Балалар бер-берсенә хәерле көн тели.)*<br>**Уен ситуациясе «Курчак юына».** *(Тәрбияче алдында су. Тәрбияче бит, кулны юу хәрәкәтен күрсәтә. Кукла хочет умываться. Предложим ей воду, помыть лицо и руки. Тәрбияче аудиоязмадан ишеткән сүзне курчакта күрсәтә.)*<br>**Аудиоязманы тыңлау.** *Аудио (44 нче кисәк)*<br>Тәрбияче: Мә, су. Бит ю, кул ю.<br>**Аудиоязманы тыңлау, күрсәтү, кабатлау.** *Аудио (45 нче кисәк) «Слушай, покажи, повтори!» — «Тыңла, күрсәт, кабатла!»*<br>**Аудиоязманы тыңлау, күрсәтү, кабатлау.** *Аудио (46 нчы кисәк) (Балалар юу хәрәкәтләрен күрсәтәләр, кабатлыйлар.)*<br>Мә су, бит ю.<br>Мә су, кул ю.<br>**Аудиоязманы тыңлау, күрсәтү, кабатлау.** *Аудио (47 нче кисәк)*<br>**Үстерелешле диалог «Иптәшеңне юынырга чакыр».** *(Тәрбияче үрнәгендә балалар бер-берсен чакыралар, биремне үтиләр, әйтәләр.)*<br>**Аудиоязмадан җыр тыңлау, кушылып җырлау.** *Аудио (48 нче кисәк) (Балалар хәрәкәт белән күрсәтәләр.)*<br>**Дәфтәрдә эш. 13 нче бирем «Кто что делает?»** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.)* | Төрле төстәге күлмәкләр.<br>Савыт белән су.<br>Уенчык курчак.<br>Аудиоязма 44–48.<br>Дәфтәрдә эш.<br>Интерактив такта. |
| **Март**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Ягымлы сүзләр.<br><br>*Сүзлек:*<br>өйрәнгән лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Дидактик уеннар өчен атрибутлар.<br>Аудиоязма 48. |
| | | **Уен ситуациясе «Хәерле көн телә».**<br>**Җыр тыңлау, кушылып җырлау.** *Аудио (48 нче кисәк)*<br>**Хәрәкәтле уен «Кайнар бәрәңге».** *(Өйрәнгән сүзләрне искә төшереп әйтү.)*<br>**Үстерелешле диалог «Иптәшеңне кунакка чакыр!»**<br>**Ситуатив күнегүләр «Поздоровайся с Акбаем».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (52 с.).<br>Курчак театры атрибутлары.<br>К.В. Закирова «Әй уйныйбыз, уйныйбыз» (168 б.). |
| | | **Уку «Три дочери».** *(Татар халык әкиятен рольләргә бүлеп.)*<br>**Мультфильм карау «Өч кыз».**<br>**Курчак театры «Өч кыз».**<br>**Җырлы-биюле уен «Зәңгәр чәчәк».** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Март**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Курчак белән уйныйбыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>күлмәк<br>чалбар<br>ки<br>сал<br>нәрсә кирәк? | **Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.** *(Һәр балада курчаклар, уенчыклар. Балалар тәрбияченең биремен кабатлап әйтәләр, үтиләр. Балалар хәрәкәт белән күрсәтәләр.) Аудио (48 нче кисәк)*<br>Мә су,<br>Бит, кул ю.<br>Чиста су, чиста су,<br>Ю, ю, ю.<br>**Дидактик уен «Курчакны юындыр».**<br>**Дидактик уен «Курчакны киендер».**<br>**Дидактик уен «Курчакны ашат».**<br>**Дидактик уен «Курчакны йоклат».**<br>**Аудиоязма «Бишек җыры».** *Аудио (43 нче кисәк)*<br>*(Балалар курчакларны тирбәтеп йоклаталар.)*<br>**Дәфтәрдә эш. 14 нче бирем «Командир».** | Дидактик уеннар өчен атрибутлар.<br>Аудиоязма 43, 48.<br>Эш дәфтәре. |
| **Март**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Шаян уенчыклар.<br><br>*Сүзлек:*<br>өйрәнгән лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Анимацион сюжет (42 тема).<br>Сборник «365 игр для дошколят» (42 с.).<br>Анимацион сюжет (42 тема). |
| | | **Дидактик уен «Курчакны чишендер».**<br>**Дидактик уен «Курчакны киендер».**<br>**Хәрәкәтле уен «Два и три».**<br>**Анимацион сюжет «Шаян уенчыклар».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (69, 235 с.). «Туган телдә сөйләшәбез» комплектына өстәмә (аудио №23–24).<br>К.В. Закирова «Иң матур сүз» хрестоматиясе (253 б.).<br>Шәүлә театры атрибутлары. |
| | | **Уку З. Туфайлова «Әни сүзе».**<br>**Уку Р.Валеева «Поздравляю тебя, мама!»**<br>**Уку Г.Зайнашева «Поздравляем бабушку».**<br>**Җыр «Әбием, әбекәем».** *(Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.)*<br>**Шәүлә театры «Минем гаиләм».** | |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Март**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Өстәл театры «Өч аю».<br><br>*Сүзлек:*<br>өстәл<br>урындык<br>карават | **Өстәл театры «Өч аю».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Әкият барышында яңа сүзләр балалар белән кабатлана.) Аудио (49 нчы кисәк)*<br>**Дидактик уен «Нәрсә юк».**<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».** *(«Зур караватъ», «кечкенә урындык», «зур өстәл» сүзтезмәләрен кулланып.)*<br>**Уен ситуациясе «Аюларга караватъ, өстәл, урындык бир».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Төрле зурлыктагы өч аю уенчыгы, өстәлләр, урындыклар, караватлар. Балалар, тәрбияче биремен тыңлап, төрле зурлыктагы җиһазларны аюларга бирәләр, әйтәләр.)*<br>— Зур аю, мә зур караватъ.<br>— Кечкенә аю, мә кечкенә урындык.<br>**Дәфтәрдә эш. 15 нче бирем «Предложи медведям мебель».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.)* | Өч аю уенчыгы.<br>Төрле зурлыктагы өстәлләр, урындыклар, караватлар.<br>Аудиоязма 49.<br>Эш дәфтәре.<br>Интерактив такта. |
| **Март**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Маша һәм өч аю.<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Дидактик уен «Нәрсә? Нинди? Ничә?»**<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».**<br>**Татар халык уены «Капкалы».**<br>**Анимацион сюжет «Маша һәм өч аю».** | Таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br><br>**Фланелеграфта әкият сөйләү «Өч аю».**<br>**Уку А.Ерикей «Четыре яблока»** *(рольләргә бүлеп).* | К.В. Закирова «На поляне детства» (204 с.).<br>Фланелеграф өчен атрибутлар. |
| **Март**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Кибеттә.<br><br>*Сүзлек:*<br>өйрәнгән лексиканы ныгыту | **Сюжетлы-рольле уен «Җиһазлар кибете».** *(Төрле зурлыктагы, төстәге җиһазларның таратма рәсемнәре. Тәрбияче сатучы ролендә.)*<br>**Сүзле уен «Кибеткә бардык, бүләк алдык».** *(Уенчыклар түгәрәк уртасында. Бер бала борылып баса. Тәрбияче уенчык күрсәтә. Балалар түгәрәктә йөри.)*<br>Тәрбияче белән балалар:<br>Мин кибеткә бардым. Әйт, Саша, нәрсә алдым?<br>**Сюжетлы-рольле уен «Уенчыклар кибете».** *(Уенчыкларны карау, исемнәрен искә төшерү: аю, куян, туп, курчак, машина, эт, песи, самолёт, поезд, барабан. Мияу и Акбай приглашают нас в магазин игрушек. Уен барлык балалар белән дәвам итә.) Аудио (50 нче кисәк)*<br>**Җырлы-биюле уен «Карусель».** *(Балалар түгәрәктә. Уенчыклар түгәрәк эчендә, һәр бала алдына куелган. Уенның сүзләрен җырлап, балалар түгәрәктә йөриләр.* | Уенчыклар: аю, куян, туп, курчак, машина, эт, песи, самолёт, поезд, барабан.<br>Аудиоязма 50–51.<br>Эш дәфтәре.<br>Интерактив такта. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | *Туктап, уенчыкларны алалар, тәрбияченең «Бу нәрсә?» соравына җавап бирәләр: «Бу — куян. Куян кечкенә, матур, чиста».) Аудио (51 нче кисәк)*<br>**Дәфтәрдә эш. 16 нчы бирем «Подарки ко дню рождения Акбая».** | |
| **Март**<br>**IV атна**<br>**4.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Ни өчен киемнәр югалган?<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Төрле төстәге күлмәкләр, чалбарлар. |
| | | **Уен ситуациясе «Курчакларга булыш!»**<br>**Сүзле-хәрәкәтле уен «Командир».**<br>**Анимацион сюжет «Ни өчен киемнәр югалган?»** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (73 с.).<br>Анимацион сюжет (45 тема). |
| | | **Концерт** *(кечкенәләр өчен).*<br>**Уку Р.Миннуллин «Сын и мама»** *(рольләргә бүлеп).*<br>**Курчак театры «Ни өчен киемнәр югалган?»** *(анимацион сюжет буенча).* | |
| **Апрель**<br>**I атна**<br>**1.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Уйнарга яратабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>яратам | **Уен ситуациясе «Уйнарга яратабыз».** *(К нам пришёл красивый зайчик. Я очень его люблю: «яратам». Вы тоже обнимите зайчика и скажите: «люблю» — «яратам».) Аудио (53 нче кисәк)*<br>**Сүзле уен «Яратам».** *(Куянны кулдан-кулга биреп, «яратам» дип әйтәләр.)*<br>**Аудиоязманы тыңлау.** *Аудио (54 нче кисәк)*<br>**Аудиоязманы тыңлау, кабатлау.** *Аудио (55 нче кисәк)*<br>**Сүзле уен «Тыңла, күрсәт, кабатла!»** *(Һәр балага санынча алма, кыяр, груша, ипи рәсемнәре таратыла. Бала аудиоязмадан ишеткән сүзтезмәгә туры килгән рәсемне таба һәм күрсәтә.) Аудио (56 нчы кисәк)*<br>**Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.** *Аудио (57 нче кисәк)*<br>**Дәфтәрдә эш. 17 нче бирем «Я люблю».** | Һәр балага җитәрлек күрсәтмә рәсемнәр: әни, әти, әби, бабай.<br>Аудиоязма 53–57.<br>Эш дәфтәре. |
| **Апрель**<br>**I атна**<br>**1.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Уенчыклар иленә сәяхәт.<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Курчак, песи, эт, туп, машина, аю, куян.<br>Аудиоязма 50–51. |
| | | **Сюжетлы-рольле уен «Уенчыклар кибете».** *Аудио (50 нче кисәк)*<br>**Түгәрәк уен «Карусель».** *Аудио (51 нче кисәк)*<br>**Сүзле-хәрәкәтле уен «Карусель».**<br>**Сүзле уен «Кибеткә бардык, бүләк алдык».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Маскалар. «Туган телдә сөйләшәбез» методик комплектына өстәмә (аудио №21–22).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (71 с.)<br>Ковробук, битлекләр. |
| | | **Театр «Туган көнгә әзерләнәбез»** *(битлекләр белән).*<br>**Җыр «Язгы тамчы»** *(тыңлау).*<br>**Уку Ф.Карим «Скоро весна».** Хрестоматия «На поляне детства» (71 с.).<br>**Ковробук-уен «Ел фасыллары».** | |

| Үткәрү вакыты | Тема Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Апрель**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Уйный-уйный үсәбез.<br><br>*Сүзлек:*<br>нәрсә бар? | **Сүзле уен «Нәрсә бар?»** *(Мияу белән Акбай уенчыклар тутырылган матур тартма тотып керәләр. Акбай и Мияу принесли нам коробку с игрушками. Давайте посмотрим, что там есть. — Нәрсә бар? Балалар алдында таныш уенчыклар.)*<br>Тәрбияче уенчыкларны күрсәтә, сорый: — Нәрсә бар?<br>Балалар: Туп бар (песи, эт, аю, курчак).<br>**Сүзле уен «Нәрсә юк?»** *(Тәрбияче үрнәгендә уенны балалар дәвам итә.)*<br>Тәрбияче: Нәрсә юк? Аю (курчак, песи, эт, туп) юк.<br>**Сүзле уен «Нәрсә бар?»** *(Балалар, уенчыкларны тотып, түгәрәккә басалар. Тәрбияче һәр баладан сорый.)*<br>Тәрбияче:<br>— Скажи, что у тебя есть?<br>— Саша, нәрсә бар?<br>— Туп бар (машина, курчак).<br>**Дидактик уен «Өстәлдә нәрсә бар?»** *(Өстәлдә уенчыклар. Балалар «Нәрсә бар?» соравына җавап бирә һәм алып күрсәтә.)*<br>**Җырлы-биюле уен «Карусель».** *Аудио (59 нчы кисәк)*<br>**Дәфтәрдә эш. 18 нче бирем «Разложи по порядку».** | Уенчыклар: курчак, песи, эт, туп, машина, аю, куян.<br>Аудиоязма 59.<br>Эш дәфтәре.<br>Интерактив такта. |
| **Апрель**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Курчакның туган көне.<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Уенчык песи, эт.<br>Яшелчә һәм уенчык муляжлары.<br>Эш дәфтәре.<br>Интерактив такта. |
| | | **Уен ситуациясе «Алиягә уенчык бүләк ит!»**<br>**Хәрәкәтле уен «Командир».**<br>**Дәфтәрдә эш. 16 нчы бирем: «Подарки ко дню рождения Акбая».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Маскалар, театр атрибутлары. К.В. Закирова «На поляне детства» (70, 239 с.).<br>«Балачак аланы» (203 б.). Анимацион сюжет (51 тема). |
| | | **«Туган көн»** *(анимацион сюжетны карау, рольләргә бүлеп уйнау).*<br>**Уку Р. Миннуллин «Люблю гостей», Н.Каштан «День рождения Айгуль».**<br>**Уку Ш.Галиев «Кунаклар».** «Балачак аланы» хрестоматиясе (203 б.). | |
| **Апрель**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | *Тема:*<br>Нәрсә бар?<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту | **Сүзле уен «Нәрсә бар?»**<br>*(Балалар, уенчыкларны тотып, түгәрәккә басалар. Тәрбияче һәр баладан сорый.)*<br>Тәрбияче: Скажи, что у тебя есть?<br>— Саша, нәрсә бар?<br>— Туп бар (машина, курчак). | Өстәл, карават, урындык. Уенчыклар.<br>Яшелчәләр. Кәрзин.<br>Аудиоязма 60.<br>Серле янчык.<br>Уенчык песи, эт. |

<table>
<tr>
<td></td>
<td></td>
<td>Уен ситуациясе «Кайда нәрсә бар?» (Өстәлдә, урындыкта, караватта уенчыклар һәм муляжлар куелган. Тәрбияче балалар белән бүлмә буйлап йөри, сорый):<br>— Бу нәрсә?<br>— Өстәл.<br>— Өстәлдә нәрсә бар?<br>— Алма бар.<br>— Бу нәрсә?<br>— Урындык.<br>— Урындыкта нәрсә бар?<br>— Туп бар.<br>— Бу нәрсә?<br>— Карават.<br>— Караватта нәрсә бар?<br>— Аю бар.<br>Җырлы-биюле уен «Кәрзиндә нәрсә бар?» (Балалар түгәрәктә. Бер бала уртада. Кулына яшелчәләр салынган кәрзин тоткан. Балалар, җырлап, түгәрәктә йөриләр.) Аудио (60 нчы кисәк)<br>Дидактик уен «Серле янчык». (Акбай белән Мияу керә. Акбайның янчыгында яшелчә муляжлары, Мияуныкында — уенчыклар. Бала янчыктагы уенчыкны капшап карый, әйтә.)<br>Акбай: Янчыкта нәрсә бар?<br>Сүзле уен «Кем бар, кем юк?» (Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. «Гаилә» темасына күрсәтмә рәсемнәр. Өйрәнгән башка темаларны да кулланып була.)<br>Тәрбияче: Монда кем бар?<br>Балалар: Әни (әти, бабай, әби, малай, кыз) бар.<br>Тәрбияче бер рәсемне алып куя, сорый: Кем юк?<br>Балалар: Әни (әти, бабай, әби, малай, кыз) юк.<br>Дәфтәрдә эш. 19 нчы бирем «Что лишнее?»</td>
<td>Яшелчә һәм уенчык муляжлары.<br>«Гаилә» темасы буенча күрсәтмә рәсемнәр.<br>Эш дәфтәре.</td>
</tr>
<tr>
<td rowspan="2">Апрель<br>III атна<br>3.2<br>(режим вакыты)</td>
<td rowspan="2">Тема:<br>Син нәрсә яратасың?<br><br>Сүзлек:<br>лексиканы ныгыту</td>
<td>Режим вакытында уен эшчәнлеге<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)</td>
<td rowspan="2">Һәр балага җитәрлек күрсәтмә рәсемнәр: әни, әти, әби, бабай.<br>Аудиоязма 53–57.<br>Эш дәфтәре.</td>
</tr>
<tr>
<td>Ситуатив күнегү «Син нәрсә яратасың?»<br>Сүзле уен «Яраткан уенчыгыңны әйт, Акбайдан сорап ал!»<br>Татар халык уены «Чүлмәк сатыш».<br>Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау «Яратам». (Аудио, 58 нче кисәк)<br>Дәфтәрдә эш. 17 нче бирем «Я люблю».</td>
</tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Сүзле уен «Үз товарыңа реклама яса».**<br>**Уку А. Хасанов «Мама сказала»** *(рольләргә бүлеп уйнау).*<br>**Әйлән-бәйлән уен «Түбәтәй», «Башмакчы».** | К.В. Закирова «На поляне детства» (61 с.).<br>Реклама өчен атрибутика.<br>К.В.Закирова «Уйный-уйный үсәбез» (169, 171 б.). |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема**<br>**Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Апрель**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Бар, юк.<br><br>*Сүзлек:*<br>бар<br>юк<br>нәрсә бар? | **Дидактик уен «Серле янчык».** *(Акбай белән Мияу керә. Акбайның янчыгында яшелчә муляжлары, Мияунықында уенчыклар.)*<br>Акбай: Нәрсә бар?<br>Мияу: Нәрсә бар?<br>**Дидактик уен «Кәрзиндә нәрсә бар?»** *(Электрон вариантта.)*<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».** *(«Бар», «юк» сүзләрен кулланып үткәрелә.)*<br>**Сүзле уен «Командир».**<br>**Сүзле уен «Кем бар, кем юк».** *(«Гаилә» темасына күрсәтмә рәсемнәр.)*<br>**Җырлы-биюле уен «Кәрзиндә нәрсә бар?»** *(Мияу һәм Акбайның алып килгән уенчыклары, яшелчә муляжлары белән.)* | Серле янчык.<br>Уенчык песи, эт.<br>Кәрзин, яшелчә муляжлары һәм уенчыклар.<br>«Гаилә» темасы буенча күрсәтмә рәсемнәр. |
| **Апрель**<br>**IV атна**<br>**4.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Кем нәрсә ярата?<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Дидактик уен «Бу нәрсә? Нинди?»**<br>**Татар халык уены «Самовар».**<br>**Анимацион сюжет «Кем нәрсә ярата?»** | Һәр балага җитәрлек күрсәтмә рәсемнәр: әни, әти, әби, бабай. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Уку Г.Тукай «Гали и Коза», «Четыре времени года».**<br>**Уку Г.Тукай «Гали белән Кәҗә», «Бу кайсы вакыт?»** *(Ике телдә дә мультфильмнар карау, әкиятләрен уку.)*<br>**Пирамида театры «Әкияттә кунакта»** *(Г.Тукай әкиятләре буенча).* | «Тылсымлы сәхифәләр» диск белән шигырьләр җыентыгы.<br>Театр атрибутлары.<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (18, 41 с.). К.В. Закирова «Балачак аланы» (44, 124 б.). |
| **Май**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Сабантуйга әзерләнәбез. | **Сюжетлы-рольле уен «Кибет».** *(Сабантуйга әзерләнәбез. Бүлмәнең төрле җирендә ашамлыклар, уенчыклар, киемнәр кибете күренешләре. Өч бала сатучы ролендә.)*<br>**а) «Киемнәр кибетендә».** *Сөйләм үрнәге:*<br>— Исәнме, Оля!<br>— Исәнме, Коля! | Ашамлык муляжлары: чәкчәк, конфет, сок, ипи, сөт, чәй.<br>Курчак киемнәре.<br>Уенчык песи, эт.<br>Аудиоязма 61–62. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *Сүзлек:*<br>мә<br>рәхмәт<br>чәк-чәк<br>конфет<br>сок<br>ипи<br>сөт<br>чәй | — Маша, күлмәк (чалбар, футболка, сарафан) бир.<br>— Нинди күлмәк кирәк?<br>— Кызыл (сары, яшел, зәңгәр) күлмәк.<br>— Мә кызыл күлмәк.<br>— Рәхмәт!<br>— Сау бул, Оля!<br>— Сау бул, Коля!<br>**ә) «Ашамлыклар кибетендә».**<br>**б) «Уенчыклар кибете».**<br>**Уен ситуациясе «Сабантуйга бүләк җыябыз».** *Аудио (61 нче кисәк)*<br>*(Завтра праздник Сабантуй. Акбай и Мияу приглашают нас на праздник. Для праздника нужны подарки, призы. Предложите им свои игрушки. Балаларның кулларында уенчыклар. Уенчык Мияу белән Акбай керәләр.)*<br>Балалар: Исәнме, Мияу! Исәнме, Акбай!<br>*Һәр бала Мияу белән Акбайга үзләренең бүләкләрен бирәләр:* Мә, Акбай, аю.<br>Акбай: Рәхмәт!<br>Бала: Мә, Мияу, туп.<br>Акбай: Рәхмәт!<br>**Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.** *Аудио (62 нче кисәк)*<br>1. Карагыз, карагыз,<br>Сабантуйга барабыз.<br>Сабантуйга барабыз,<br>Уйнап бүләк алабыз.<br>2. Сабантуйга барабыз,<br>Сикерәбез, чабабыз.<br>Җырлап-биеп алабыз,<br>Уйнап бүләк алабыз. | |
| **Май**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Без театр уйныйбыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Үстерешле диалог «Мә бүләк», «Нинди? Ничә?»**<br>**Татар халык көенә күмәк бию.**<br>**Хәрәкәтле уен «Кыңгырау».** *(Санау, боерык бирү, ягымлы сүз.)*<br>**Аудиоязма тыңлау, кушылып җырлау. «Матур бакча».** | Битлекләр, ашамлык муляжлары, уенчыклар.<br>«Уйный-уйный үсәбез» (58 б.). |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br><br>**Бармак театры «Өч аю».**<br>**Уку Р.Вәлиева «Җиңү көнендә».**<br>**Уку Р.Валеева «День победы».**<br>**Өстәл театры «Минем бабай солдат булган».** | К.В. Закирова «На поляне детства» (236–237 с.).<br>К.В. Закирова «Балачак аланы» (524 б.).<br>Ковробук. |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Май**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Күңелле Сабантуй уеннары.<br><br>*Сүзлек:*<br>йөгер<br>сикер<br>уйна<br>җырла<br>бие | **Анимацион сюжет карау «Сабантуй бәйрәме».** *(Анимацион сюжет эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү. Анимацион сюжет геройлары булып уйнап карау.)*<br>**Сюжетлы-рольле уен «Кибет».** *(Сабантуйга әзерләнәбез. Бүлмәнең төрле почмагында ашамлыклар, уенчыклар, киемнәр кибете күренешләре. 3 бала сатучы ролендә.)*<br>**а) «Киемнәр кибетендә».**<br>**ә) «Ашамлыклар кибетендә».**<br>**б) «Уенчыклар кибете».**<br>**Җырлы-биюле уеннарны кабатлау.**<br>— «Минем өем» — сүзләрен искә төшерү, җырлау.<br>— «Бар матур бакча».<br>— «Төсле туплар».<br>— «Матур көлмәк». | Уенчыклар, муляжлар, рәсемнәр, төсле туплар.<br>5–6 яшьлекләр өчен видео-кушымта (анимацион фильмнар дискы). |
| **Май**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Биибез дә, җырлыйбыз да.<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Түгәрәк уен «Матур бакча».**<br>**Җыр «Яратам».**<br>**Татар халык уены «Яз, балалар, яңгыр». Татар халык биюе «Әпипә».** | «Уйный-уйный үсәбез» (66 б.). |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Мультфильм «Төлке белән Каз»** *(сәхнәләштерү).*<br>**Уку Г.Морат «Сабантуй».**<br>**Уку Э.Блинова «Сабантуй».**<br>**Анимацион сюжет карау «Сабантуй бәйрәме».** | Театр атрибутлары, маскалар.<br>К.В. Закирова «Балачак аланы» (527 б.).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (237 с.).<br>Анимацион сюжет (55 тема). |
| **Май**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Сабантуй бәйрәме.<br><br>*Сүзлек:*<br>лексиканы ныгыту. | **«Сабантуй» җыры.** *(Балалар, «Сабантуй» җырын җырлап, мәйданда бәйрәмне башлыйлар. Уеннарны тәрбияче оештыра һәм командаларын татарча бирә: «Йөгер», «Сикер», «Уйна», «Җырла», «Бие».)*<br>**Уеннар:**<br>1. «Капчык киеп сикерү».<br>2. «Агач кашыкка йомырка салып йөгерү».<br>3. «Ат чабышы».<br>4. «Чүлмәк вату».<br>**Күмәк бию.** | Сабантуй уеннары өчен атрибутлар.<br>Аудиоязма 63. |

<table>
<tr>
<td rowspan="4">Май<br>IV атна<br>4.2<br>(режим вакыты)</td>
<td rowspan="4">Тема:<br>Бездә Сабантуй.<br><br>Сүзлек:<br>лексиканы ныгыту</td>
<td>Режим вакытында уен эшчәнлеге<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)</td>
<td rowspan="2">Сабантуй бәйрәменә атрибутлар.</td>
</tr>
<tr>
<td>Сүзле уен «Бүләкләр җыябыз». (Нәрсә? Нинди? Ничә?)<br>Хәрәкәтле уеннар «Ат чабышы», «Капчык киеп йөгерү», «Чүлмәк вату», «Чиләк белән су ташу»...<br>Мультфильм «Сабантуй».</td>
</tr>
<tr>
<td>Өстәмә материал<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)</td>
<td rowspan="2">К.В. Закирова «На поляне детства» (237–238 с.).<br>Маскалар.</td>
</tr>
<tr>
<td>«Сабантуй бәйрәме котлы булсын!» (Милли киемнәрдәге балалар башка төркем балаларын, ата-аналарын котлыйлар.)<br>Уку Ш.Галиев «Батыр Сабантуя», Р.Корбан «Сабантуй».<br>Без театр уйныйбыз «Сабантуй».</td>
</tr>
</table>

## «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР — МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» проектының тематик планы
(5–6 яшьлек балалар өчен)

**Лексик минимум** — якынча 60 сүз.
**Үзләштерү өчен тәкъдим ителгән сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, йоклый, утыра, ашый, ашыйм, эчә, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, йөгер, йөгерәм, чәкчәк, өчпочмак, яшь, төлке, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр; Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Нишлисең? Кая барасың? Син нишлисең? Нәрсә яратасың?
**Проектның эчтәлеге:** уртанчылар, зурлар төркемендә өйрәнгән сүзләргә таянып аралашуга корылган.

**Сөйләм үрнәкләре:**
— Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби)!
— Хәерле көн, Оля (Коля)!
— Песи нишли?
— Песи йоклый.

— Әни нишли?
— Әни утыра.

— Коля нишли?
— Коля ашый (эчә).

— Мияу, нишлисең?
— Ашыйм.
— Акбай, нишлисең?
— Эчәм.

— Оля (Коля), нишлисең?
— Уйныйм.

— Кая барасың?
— Кафега барам.

— Син нишлисең?
— Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклыйм).

Туп, туп,
Матур туп.
Сикер-сикер,
Матур туп.

Куян сикерә (йөгерә).
Туп сикерә.
Песи сикерә (йөгерә).
Төлке сикерә (йөгерә).

— Йөгер! Син нишлисең?
— Мин йөгерәм.

— Мин чәкчәк ашыйм.
— Мин өчпочмак ашыйм.

— Сиңа ничә яшь?
— Миңа 6 яшь.

— Мин бүре. Мин зур, матур, чиста.

Әтәч зур, матур.
Тавык кечкенә, матур.

— Син кем?
— Мин үрдәк.

Куян чана шуа.

Мин чана шуам.

— Аю, әйдә бие!
— Оля кызыл шар ярата?
— Юк.
— Оля яшел шар ярата?
— Әйе, мин яшел шар яратам.

— Син нишлисең?
— Мин җырлыйм.

Җырлыйбыз.
Зур рәхмәт.

Кыз китап укый.

Рәсем ясыйм — алма ясыйм.
Мәктәп.

— Кем укый?
— Мин укыйм.

Бик тәмле.

Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә.
Теремкәйдә тычкан яши.
Теремкәйдә куян яши.
Теремкәйдә бүре яши.
Теремкәйдә төлке яши.
Теремкәйдә аю яши.
Алар бик дус.

— Кәҗә кая?
— Әнә кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.

— Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?
— Мин сөт яратам. Сөт тәмле.

— Мә, кәҗә, ботка аша.
— Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.

# «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР — МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» проекты

(6–7 яшьлек балалар өчен)

**Максат:**
Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

**Бурычлар:**
1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Сентябрь**<br>**I атна**<br>**1.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Әйдәгез танышабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>син кем? | **Уен ситуациясе «Әйдәгез танышабыз».**<br>Тәрбияче: Исәнмесез, балалар!<br>Балалар: Исәнмесез, ... !<br>Тәрбияче: Хотите узнать как меня зовут, спросите по-татарски:<br>Син кем? Син — син, кем — кем, син кем, син кем?<br>Тәрбияче: Мин ... . Син кем?<br>Балалар: Мин Оля (Коля). (Шул рәвешле, тәрбияче һәр баладан сорый.)<br>**Уен ситуациясе «Мияу кунакта».** *Аудио (1 нче кисәк)*<br>*Ишек шакыган тавыш (озын пауза).*<br>Тәрбияче: Син кем? Не отвечает. Интересно, кто же это?<br>Дети, помогите мне. Наверное, хочет, чтобы спросили все вместе.<br>Тәрбияче: Син кем?<br>Бергә: Син кем?<br>Тәрбияче: Молчат. Давайте, спросим погромче. Син кем?<br>Бергә: Син кем?<br>Мияу: Мин песи. Мин Мияу.<br>Тәрбияче: А-а, это наш друг Мияу, давайте, позовём его.<br>Бергә: Мияу, кил монда!<br>*(Ишек ачылган тавыш, кыска пауза.)*<br>Мияу керә: Исәнмесез!<br>Балалар: Исәнме, Мияу! Хәлләр ничек?<br>Мияу: Әйбәт *(кыска пауза).*<br>Балалар: Мияу, утыр.<br>Мияу: Рәхмәт! | Уенчык Мияу.<br>Курчак, туп.<br>Аудиоязма 1–2. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Тәрбияче: Мияу хочет познакомиться с вами. Поиграем с мячом в игру «Син кем?»<br>**Сүзле уен «Син кем?»** *(Балалар түгәрәктә басып торалар. Мияу, балага туп биреп: «Мин Мияу. Син кем?» — дип сорый. Балалар, шул үрнәктә, бер-берсеннән сорап уенны дәвам итәләр.)*<br>Бала: Син кем?<br>Бала: Мин Оля (мин кыз).<br>**Аудиоязма тыңлау.** *Аудио (1 нче кисәк).*<br>— Ребята, слушайте, как знакомятся Оля с Колей.<br>Оля: Исәнме!<br>Коля: Исәнме!<br>Оля: Син кем?<br>Коля: Мин Коля. Син кем?<br>Оля: Мин Оля.<br>**Диалог: «Син кем?»** *(Аудиоязма үрнәгендә бала белән бала диалогы.)* | |
| **Сентябрь**<br>**I атна**<br>**1.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Син кем?<br><br>*Сүзлек:*<br>син кем? | **Уен ситуациясе «Әйдәгез танышабыз».**<br>**Уен ситуациясе «Мияу кунакта».**<br>**Сүзле уен «Син кем?»**<br>**Аудиоязма тыңлау.** *Аудио (1–2 нче кисәк)*<br>**Диалог «Син кем?»** *(Аудиоязма үрнәгендә бала белән бала диалогы.)*<br>**Дидактик уен: «Парын тап».** *(Лото принцибы буенча, гаилә рәсемнәрен кулланып, балада әти рәсеме булса, ул, өстәлдән әти рәсемен табып, парлаштырырга тиеш.)* | Уенчык Мияу.<br>Курчак, туп, гаилә рәсемнәре.<br>Аудиоязма 1–2. |
| **Сентябрь**<br>**I атна**<br>**1.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Әйдәгез танышабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>син кем? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Уен ситуациясе «Әйдәгез танышабыз».**<br>**Сүзле уен «Үзең турында сөйлә».**<br>Бала: Син кем?<br>Бала: Мин кыз (малай).<br>Бала: Нинди?<br>Бала: Мин зур, матур, чиста кыз (малай).<br>**Дидактик уен «Парын тап».**<br>**Сүзле уен «Син кем?».**<br>**Уен ситуациясе «Мияу кунакта».**<br>**Дидактик уен «Кем юк?»** *(Тәрбияче тактага гаилә әгъзалары рәсемнәрен элә. Бер рәсемне яшерә һәм сорый: Кем юк?)*<br>**Җырлы уен «Кишер үстерәбез».** *Аудио (1 нче кисәк, анимацион сюжетка таянып, — нинди? соравын аңлап, дөрес җавап бирергә өйрәтү. Баллы, зур, чиста, пычрак, тәмле.)* | Уенчык Мияу.<br>Курчак, туп, гаилә рәсемнәре.<br>Аудиоязма 1–2. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова. «На поляне детства» (38, 70 с.).<br>К.В. Закирова «Бала-чак аланы» (374 б.).<br>«Уйный-уйный үсәбез» проекты.<br>Анимацион сюжет (6 тема). |
| | | **А.Алиш әкиятләре буенча мультфильмнар карау.** *(«Тукмар белән Чукмар», «Куян кызы», «Каз белән Аккош»).*<br>**«Баллы кишер» анимацион сюжетын карау.** *(«Уйный-уйный үсәбез» проекты буенча, эчтәлеге буенча сөйләшү.)*<br>**Уку А.Гаффар «Сладкий щавель».**<br>**Уку Р.Миннуллин «Люблю гостей».**<br>**Уку Йолдыз «Кунакка килегез».** | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема<br>Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Сентябрь<br>II атна<br>2.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Хәерле көн.<br><br>*Сүзлек:*<br>хәерле көн | **Уен ситуациясе «Акбай белән Мияу бездә кунакта».** *Аудио (3 нче кисәк)*<br>*(Ишек шакыган тавыш, озын пауза.)*<br>Бергә: Син кем?<br>Акбай: Мин эт, Акбай. Һау-һау.<br>Мияу: Мин песи, Мияу. Мияу-мияу.<br>Бергә: Акбай, кил монда!<br>Мияу, кил монда!<br>Акбай, Мияу: Исәнмесез, балалар!<br>Балалар: Исәнмесез, Акбай, Мияу!<br>**Уен ситуациясе «Хәерле көн».**<br>Тәрбияче: Ребята, а теперь пожелаем им доброго дня. «Добрый день!» — «Хәерле көн!»<br>Бергә: Хәерле көн!<br>Акбай, Мияу: Хәерле көн!<br>*(Һәр бала Акбай белән Мияуга хәерле көн телиләр.)*<br>Коля: Хәерле көн, Акбай!<br>Акбай: Хәерле көн, Коля!<br>Оля: Хәерле көн, Мияу!<br>Мияу: Хәерле көн, Оля!<br>**Сүзле уен «Хәерле көн».** *(Балалар түгәрәктә, бер-берсенә хәерле көн телиләр.)*<br>Саша: Хәерле көн, Маша!<br>Маша: Хәерле көн, Саша!<br>**Үстерешле диалог «Телефоннан сөйләшәбез».** *Аудио (4 нче кисәк)*<br>Акбай: Алло.<br>Мияу: Алло. Син кем?<br>Акбай: Мин Акбай.<br>Мияу: Исәнме, Акбай! | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Уенчык телефоннар.<br>Аудиоязма 3–5. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Акбай: Хәерле көн, Мияу! Хәлләр ничек?<br>Мияу: Әйбәт. Рәхмәт! Акбай, хәлләр ничек?<br>Акбай: Әйбәт. Рәхмәт! Сау бул, Мияу!<br>Мияу: Сау бул, Акбай!<br>*(Шул үрнәктә балалар бер-берсе белән телефоннан сөйләшәләр.)*<br>**Аудиоязма тыңлау, җырлау.** *Аудио (5 нче кисәк)*<br>**Җыр. «Хәерле көн».**<br>Хәерле көн, әти!<br>Хәерле көн, әни!<br>Хәерле көн, бабай!<br>Хәерле көн, әби! | |
| **Сентябрь**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Ягымлы сүзләр.<br><br>*Сүзлек:*<br>хәерле көн | **Уен ситуациясе «Акбай белән Мияу бездә кунакта».**<br>**Уен ситуациясе «Хәерле көн».**<br>**Сүзле уен «Хәерле көн».**<br>**Үстерешле диалог «Телефоннан сөйләшәбез».**<br>**Аудиоязма тыңлау, җырлау.**<br>**Дидактик уен «Тәрҗемәче».**<br>*(I вариант. Тәрбияче балаларга рус телендә ягымлы сүзләр әйтә, бала шул сүзне тәрҗемә итеп татарча әйтергә тиеш.)*<br>*(II вариант. Балалар түгәрәктә тора. Бер бала янында торган икенче балага тупны бирә, русча ягымлы сүз әйтә. Туп тоткан бала сүзнең тәрҗемәсен татарча әйтә. Уен шулай дәвам итә.)* | Уенчык Акбай, Мияу, туп.<br>Уенчык телефоннар.<br>Аудиоязма 3–5. |
| **Сентябрь**<br>**II атна**<br>**2.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Мияу адашкан.<br><br>*Сүзлек:*<br>хәерле көн | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Дәфтәрдә эш. 1 нче бирем «Ягымлы сүзләр».**<br>**Дидактик уен «Ничә?»** *(«Гаилә, «Яшелчә», «Савыт-саба», «Уенчыклар» темаларына караган рәсемнәр буенча санау.)*<br>**Уен ситуацияләре «Акбай белән Мияу бездә кунакта», «Хәерле көн».**<br>**Дидактик уен «Тәрҗемәче».** *(Ягымлы сүзләр.)*<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».** *(Уенда ягымлы сүзләр кулланыла. Тәрбияче бер баланың колагына бер ягымлы сүз әйтә. Шул сүзне, пышылдап, балалар бер-берсенә әйтәләр. Соңгы бала пышылдап әйткән сүзне кычкырып әйтә. Сүзнең дөреслеге тикшерелә.)*<br>**Дидактик уен «Бу кем?»**<br>**Үстерешле диалог «Телефоннан сөйләшәбез».**<br>**Сүзле уен «Син кем?»**<br>**«Командир» уены.**<br>**Сүзле уен «Җырлап әйт».** | Уенчык Мияу, туп.<br>Гаилә, яшелчә, савыт-саба, уенчык темаларына караган рәсемнәр яки муляжлар. Эш дәфтәре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Анимацион сюжет карау: «Мияу адашкан»** *(әчтәлеге буенча әңгәмә).*<br>**Театральләштерелгән уен ситуациясе «Без шалкан утыртабыз».**<br>**Уку «Шалкан» әкияте.**<br>**Аз хәрәкәтле уен: «Ачык авыз», «Әйдә танышабыз».** | Анимацион сюжет (3 тема).<br>«Шалкан» әкияте персонажлары маскалары.<br>К.В. Закирова. «Иң матур сүз» (25 б.).<br>К.В. Закирова «Әй уйныйбыз-уйныйбыз» (173-174 б.). |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема**<br>**Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Сентябрь**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Син кем?<br><br>*Сүзлек:*<br>тычкан | **Уен ситуациясе «Шалканны кемнәр тарткан?»**<br>Тәрбияче: Ребята, вы помните сказку про репку? Кто посадил и вырастил большую репку? Кем?<br>Бергә: Бабай.<br>Тәрбияче: Кто помог вытащить репку? Назовите их по-татарски.<br>Бергә: Әби, кыз, эт, песи, мышь — тычкан.<br>*(«Тычкан» сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.)*<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».** *(Уенда «кечкенә тычкан», «матур тычкан» сүзтезмәләре кулланыла.)*<br>**Дидактик уен «Кем юк?»** *(Уенда «Шалкан» әкияте өстәл театры персонажлары кулланыла.)*<br>**Сүзле уен: «Син кем?»** *Аудио (6 нчы кисәк)*<br>Акбай и Мияу тоже хотят играть с нами в сказку «Репка». Они должны хорошо запомнить ваши имена. Давайте проверим. Акбай отвернётся, а вы по очереди будете подходить и здороваться с ним. Акбай будет угадывать, кто это.<br>Мияу: Исәнме, Акбай!<br>Акбай: Син кем? Оля?<br>Мияу: Юк, мин Мияу.<br>*(Шул үрнәктә балалар Акбай белән уенны дәвам итәләр.)*<br>**Уен ситуациясе «Без шалкан утыртабыз».** *(Тәрбияче балаларга әти, әни, әби, бабай, кыз, малай, эт, песи, тычкан рольләрен бүлеп бирә, битлекләрен тарата).*<br>Тәрбияче: Мы посадим свою репку. Она будет ещё больше. Чтобы её вытащить, нужно кого-то позвать. Давайте позовём и маму, и папу. Как позовём?<br>Бергә: Әти, кил монда! Әни, кил монда!<br>**Сүзле уен «Җырлап әйт».**<br>Балалар, түгәрәктә җырлап: Син кем?<br>*(Битлек кигән бала, уртага чыгып җырлап: — Мин бабай.*<br>*Уен барлык персонажлар (әби, әти, әни, кыз, малай, эт, песи, тычкан) белән шулай дәвам итә.)* | Уенчык Акбай, Мияу.<br>«Шалкан» әкияте өстәл театры персонажлары: әти, әни, әби, бабай, кыз, малай, эт, песи, тычкан.<br>Битлекләр: әти, әни, әби, бабай, кыз, малай, эт, песи, тычкан.<br>Аудиоязма 6. |

<table>
<tr>
<td>Сентябрь<br>III атна<br>3.2<br>Төп белем бирү эшчәнлеге</td>
<td>Тема:<br>«Шалкан» әкия-<br>тен сәх-<br>нәләштерү.<br><br>Сүзлек:<br>бу кем?</td>
<td>Сүзле уен «Бу кем?» (Акбай белән Мияу әти, әни, кыз, малай, әби, бабай, тычкан рәсемнәрен алып киләләр.)<br>Мияу (бер рәсемне күрсәтеп): Бу кем?<br>Бергә: Бу әни (әти, кыз, малай, әби, бабай, тычкан).<br>Дидактик уен «Бу кем?» (Уенда «Шалкан» (үзебез чыгарган әкият) әкияте персонажлары рәсемнәре яки уенчыклары кулланыла. Мияу борылып баса. Акбай, «әти» рәсемен күрсәтеп, Мияудан сорый.)<br>Акбай: Бу кем?<br>Мияу: Бу әти.<br>Акбай: Әйе, әти. Бу кем? (Бабай рәсемен күрсәтеп.)<br>Мияу: Бу әни.<br>Акбай: Юк. Бу кем?<br>Мияу: Бу кыз.<br>Акбай: Юк. Бу кем?<br>Мияу: Бу бабай.<br>Акбай: Әйе, бу бабай.<br>(Шул үрнәктә балалар уенны дәвам итә.)<br>Аудиоязма тыңлау. Аудио (8 нче кисәк)<br>Слушайте, спросите: Это кто? — Бу кем?<br>— Исәнмесез (әни тавышы, озын пауза)!<br>— Бу кем? (Балалар сорый.)<br>— Бу әни (әни тавышы).<br>— Исәнмесез (әти тавышы, озын пауза)!<br>— Бу кем? (Балалар сорый.)<br>— Бу әти (әти тавышы).<br>— Хәерле көн, мыр-р-р... (песи тавышы, озын пауза).<br>— Бу кем? (Балалар сорый.)<br>— Бу песи (песи тавышы).<br>— Хәлләр ничек? Р-р-р... (эт тавышы, озын пауза).<br>— Бу кем? (Балалар сорый.)<br>— Бу эт (эт тавышы).<br>— Чи, чи, чи. Исәнмесез.<br>— Бу кем? (Балалар сорый.)<br>— Бу тычкан (тычкан тавышы).<br>«Шалкан» әкиятен сәхнәләштерү. (Балаларга рольләр бүлеп бирелә.)<br>— Син кем?<br>— Мин бабай (әни, әти, кыз, малай, әби, тычкан).</td>
| **Декабрь**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Бәйрәмгә барабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>чәкчәк<br>өчпочмак | **Уен ситуациясе «Билет сорап ал».** *(Акбай кассир ролендә.)*<br>*Аудио (25 нче кисәк)*<br>— Акбай и Мияу собрались в Казань. Покупают в кассе билет *(хатын-кыз тавышы).*<br>Мияу: Акбай, билет бир әле.<br>Акбай: Кая барасың?<br>Мияу: Казанга барам.<br>Акбай: Мә билет.<br>Мияу: Рәхмәт!<br>— Мы с вами тоже поедем в город Казань. Спросите у кассира билет *(хатын-кыз тавышы).*<br>*(Шул үрнәктә балалар билет сорап алалар.)*<br>**Аудиоязма тыңлау.** *Аудио (26 нчы кисәк)*<br>— Мы проезжаем заповедную зону. Тут обитают дикие животные, которые охраняются *(пауза).* Ребята, скажите, кого вы видите? Что они делают? *(Ир-ат тавышы.)*<br>*(Аудиоязманы тыңлаганнан соң балалар җавабы. Тәрбияче сюжетлы рәсемнәр күрсәтә.)*<br>Тәрбияче:<br>— Бу төлке. Төлке утыра.<br>— Бу тычкан. Тычкан ашый.<br>— Бу куян. Куян сикерә.<br>— Бу аю. Аю йоклый.<br>**Аудиоязма тыңлау.** *Аудио (27 нче кисәк)*<br>— Остановка для отдыха. Здесь можно поесть и попить *(ир-ат тавышы).*<br>Акбай: Мин өчпочмак ашыйм. Син нишлисең?<br>Мияу: Мин чәкчәк ашыйм.<br>**Аудиоязма тыңлаганнан соң диалог.**<br>Коля: Мин өчпочмак ашыйм.<br>Оля: Мин бәрәңге ашыйм. | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Сюжетлы рәсемнәр: төлке утыра, тычкан ашый, куян сикерә, аю йоклый.<br>Билетлар.<br>Аудиоязма 25–28. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Саша: Мин лимонад эчәм.<br>**Аудиоязмадан җыр тыңлау, җырлау.** *Аудио (28 нче кисәк)*<br>Мин барам, барам, барам,<br>Казанга барам, барам.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Казанга барам, барам. | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема<br>Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Декабрь<br>IV атна<br>4.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Мин барам.<br><br>*Сүзлек:*<br>барам<br>кая бара-сың?<br>нишлисең? | **Диалог «Син нишлисең?»**<br>**Уен ситуациясе «Йөгерәм».**<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».**<br>**Уен-эстафета «Кем тизрәк».**<br>**Ситуатив күнегү. «Син нишлисең?»**<br>**Үстерешле диалог «Нәрсә кирәк?»** | Эмблемалар.<br>Туплар.<br>Эш дәфтәрләре.<br>Аудиоязма 24.<br>Схема-пиктограмма-лар.<br>Таратма рәсемнәр. |
| **Декабрь<br>IV атна<br>4.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Көчлеләр, кыюлар, җитезләр.<br><br>*Сүзлек:*<br>йөгер<br>йөгерәм<br>чәкчәк<br>өчпочмак | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Үстерешле диалог «Син кая барасың?»**<br>**Уен ситуациясе «Билет бир әле».**<br>**Уен ситуациясе «Спорт бәйрәменә барабыз».**<br>**«Командир» уены.**<br>**Сүзле уен «Син нишлисең?»**<br>**Сюжетлы рәсемнәр буенча диалог төзү.** *Аудио (27–28 нче кисәкләр)*<br>**Сүзле уен «Тылсымлы транспорт»** *(транспорт төрләрен уйлап табу).*<br><br>**Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br><br>**«Көчлеләр, кыюлар, җитезләр» анимацион сюжетын карау** *(эчтәлеге буенча әңгәмә).*<br>**«Көчлеләр, кыюлар, җитезләр» анимацион сюжетын сәхнәләштерү.**<br>**Җырны тыңлау һәм кушылып җырлау.** *Аудио (29 нчы кисәк)*<br>*(Тәрбияче үрнәге буенча әйлән-бәйлән уены: «Барам, барам». «Тылсымлы транспорт» уенына таянып.)*<br>Мин барам, барам, барам,<br>Мин автобуста барам, барам... | Эмблемалар.<br>Туплар.<br>Эш дәфтәрләре.<br>Аудио № 24.<br><br>Анимацион сюжет (24 тема).<br>Төрле хайван маскалары.<br>Аудиоязма 29. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Гыйнвар**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Казанда спорт бәйрәме.<br><br>*Сүзлек:*<br>сиңа ничә яшь? | **Үстерешле диалог «Интервью бирү».** *Аудио (29 нчы кисәк)*<br>*(Балаларда сикерү, йөгерү хәрәкәте белдерүче эмблемалар.)*<br>Тәрбияче *(корреспондент ролендә):* Исәнме, мин корреспондент! Син кем?<br>Акбай: Исәнмесез! Мин Акбай.<br>Тәрбияче: Сиңа ничә яшь?<br>Акбай: 6 яшь.<br>Тәрбияче: Син нишлисең? *(Эмблемага күрсәтеп.)*<br>Акбай: Мин сикерәм (йөгерәм).<br>Тәрбияче: Рәхмәт!<br>*(Шул үрнәктә корреспондент Мияудан интервью ала.)*<br>**Үстерешле уен «Сөйләшәбез».** *(Балалар үзләре бер-берсеннән интервью алалар.)*<br>**Уен ситуациясе «Зарядка ясыйбыз».** *(Балалар, 10-га кадәр санап, төрле гимнастик хәрәкәтләр ясыйлар.)*<br>Әй, нәниләр, нәниләр,<br>Ардык без, дип әйтмиләр.<br>Аякларын күтәреп,<br>Матур итеп атлыйлар.<br>Хәзер барабыз алга,<br>Егылмыйча, син атла.<br>1, 2, 3, 4, 5.<br>Хәзер барабыз артка,<br>Егылмыйча, син атла.<br>6, 7, 8, 9, 10.<br>Егылмыйча, син атла.<br>1, 2, 3, 4, 5.<br>Хәзер барабыз артка,<br>Егылмыйча, син атла.<br>6, 7, 8, 9, 10.<br>**Уен-эстафета «Кем тизрәк?»** *(Балалар ике командага бүленә. Эстафета өчен һәр командага берәр шар бирелә. Беренче бала, шарны тотып, билгеләнгән урынны сикереп әйләнеп килә, икенче балага шарны бирә.)*<br>Бала: Оля, мә шар, сикер.<br>*(Уен шул рәвешле дәвам итә.)*<br>**Уен-эстафета «Кем тизрәк?»** *(Балалар ике командага бүленә. Эстафета өчен һәр командага берәр туп бирелә. Беренче бала, тупны тотып, билгеләнгән урынны йөгереп әйләнеп килә, икенче балага тупны бирә.)*<br>Бала: Оля, мә туп, йөгер.<br>*(Уен шул рәвешле дәвам итә.)* | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Микрофон.<br>Эмблемалар: йөгерүчеләр, сикерүчеләр хәрәкәте белдерүче.<br>Аудиоязма 29. |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Гыйнвар<br>III атна<br>3.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Спорт бәйрәмендә.<br><br>*Сүзлек:*<br>яшь<br>сиңа ничә яшь? | **Үстерешле уен «Сөйләшәбез, серләшәбез».**<br>**«Интервью бирү» («Син нишлисең?»)**<br>**Уен ситуациясе «Зарядка ясыйбыз».**<br>**Уен-эстафета «Кем тизрәк?»**<br>**Уен ситуациясе «Йөгерәм, сикерәм, уйныйм».**<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».** | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Микрофон.<br>Эмблемалар: йөгерүчеләр, сикерүчеләр хәрәкәтен белдерүчеләр. |
| **Гыйнвар<br>III атна<br>3.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Казанда спорт бәйрәме.<br><br>*Сүзлек:*<br>яшь<br>сиңа ничә яшь? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **Үстерешле диалог «Интервью бирү».** *Аудио (30 нчы кисәк)*<br>**Сүзле уен «Балыкчы»** *(магнитлы сюжетлы рәсемнәр белән).*<br>*(«Нишли?» грамматик конструкциясен ныгыту.)*<br>**Уен ситуациясе «Зарядка ясыйбыз».** *Аудио (31–32 нче кисәкләр)*<br>**Уен-эстафета «Кем тизрәк?»**<br>**Сүзле уен «Үзеңне яисә дустыңны макта».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | М.Җәлил әсәрләре буенча эшләнгән мультфильмнар.<br>Эш дәфтәре.<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (188–189 с.). |
| | | **М.Җәлил әсәрләре буенча диск театры («Күке», «Әтәч»).**<br>**Уку. М.Файзуллина «Четыре художника».**<br>**М.Җәлил әсәрләре буенча рәсем бәйгесе («Күке», «Әтәч», «Маэмай», «Көз җитте»).**<br>**«Кайда булдым, мин әйтмим, хәрәкәтен күрсәтәм» уены буенча хәрәкәтләрне кабатлап күрсәтү.** | |
| **Гыйнвар<br>IV атна<br>4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Уеннар эстафетасы.<br><br>*Сүзлек:*<br>яшь<br>сиңа ничә яшь?<br>бүре<br>керпе | **Уен ситуациясе «Зарядка ясыйбыз».** *(Балалар, 10-га кадәр санап, төрле гимнастик хәрәкәтләр ясыйлар.)*<br>Әй, нәниләр, нәниләр,<br>Ардык без, дип әйтмиләр.<br>Аякларын күтәреп,<br>Матур итеп атлыйлар.<br>Хәзер барабыз алга,<br>Егылмыйча, син атла.<br>1, 2, 3, 4, 5.<br>Хәзер барабыз артка,<br>Егылмыйча, син атла.<br>6, 7, 8, 9, 10. | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Микрофон.<br>Эмблемалар: йөгерүчеләр, сикерүчеләр хәрәкәтен белдерүчеләр.<br>Шар (2 данә).<br>Бүләкләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Егылмыйча, син атла.<br>1, 2, 3, 4, 5.<br>Хәзер барабыз артка,<br>Егылмыйча, син атла.<br>6, 7, 8, 9, 10.<br>**Уен-эстафета «Кем тизрәк?»** *(Балалар ике командага бүленә. Эстафета өчен һәр командага берәр шар бирелә. Беренче бала, шарны тотып, билгеләнгән урынны сикереп әйләнеп килә, икенче балага шарны бирә.)*<br>Бала: Оля, мә шар, сикер.<br>*(Уен шул рәвешле дәвам итә.)*<br>**Пиктограммалар белән эш.**<br>**«Командир» уены.**<br>**Уен-эстафета «Кем тизрәк?»**<br>**Ситуатив күнегү. «Син нишлисең?»**<br>**Җырлы-хәрәкәтле уен «Зарядка ясый нәниләр».** | |
| **Гыйнвар**<br>**IV атна**<br>**4.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Эстафетада катнашабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>яшь<br>сиңа ничә яшь?<br>бүре<br>керпе | **Үстерешле уен «Сөйләшәбез, серләшәбез».**<br>**Үстерешле диалог «Интервью бирү» («Син нишлисең?»).**<br>**Уен ситуациясе «Зарядка ясыйбыз».**<br>**Уен-эстафета «Кем тизрәк?»**<br>**Уен ситуациясе «Йөгерәм, сикерәм, уйныйм».**<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».** | Уенчык Акбай, Мияу, рәсемле картиналар, ашамлык муляжлары. Микрофон. |
| **Гыйнвар**<br>**IV атна**<br>**4.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Җәнлекләр спорт бәйрәмендә.<br><br>*Сүзлек:*<br>яшь<br>сиңа ничә яшь?<br>бүре<br>керпе | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Уен ситуациясе «Циркка барабыз».**<br>**Үстерешле (сүзле) уен «Син кая барасың?»**<br>**Дидактик күнегү «Кем күбрәк күрә, әйтә һәм җыя?»** *(«Хайваннар» һәм «Уенчыклар» темалары буенча лексиканы ныгыту. Аңлатма: урамда мәйданчыкның төрле җирләренә уенчыклар урнаштырылган, балалар шуларны күреп әйтергә һәм алып килеп бирергә тиеш булалар.)*<br>**«Командир» уены.**<br>**Хәрәкәтле уен «Тылсымлы транспорт».** *(Балалар тәрбияче күрсәткән рәсемнәр буенча транспорт төрләрен сайлап алалар, хәрәкәттә күрсәтәләр.)*<br>**Уен ситуациясе «Үзең турында сөйлә».**<br>**Сүзле уен «Кем нәрсә ярата?** *(«Хайваннар» һәм «Ашамлыклар» темалары буенча лексиканы ныгыту.)* | Уенчыклар, рәсемле картиналар, ашамлык муляжлары. |

<table>
<tr><td></td><td></td><td>Сүзле уен «Уенчык турында сөйлә». (Урамда уйналган «Кем күбрәк күрә, атый һәм җыя?» уенына таянып.)</td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>Өстәмә материал<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)</td><td rowspan="2">Анимацион сюжет (27 тема).</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>«Җәнлекләр спорт бәйрәмендә» анимацион сюжетын карау (эчтәлеге буенча әңгәмә).<br>«Җәнлекләр спорт бәйрәмендә» анимацион сюжетын сәхнәләштерү.<br>Сәхнәләштерелгән уен ситуациясе «Нәрсә юк?», «Нишли?», «Нишлисең?»<br>Хәрәкәтле уен «Яулык». (Балалар, битлекләр киеп, түгәрәктә басып торалар, куллары артта. Уенны алып баручы түгәрәк буенча йөри, музыка туктагач, яулыкны бер баланың кулына куеп китә. Кемдә яулык, шул уенны дәвам итә.)<br>Татар халык уены «Йөзек салыш».<br>«Мы из Чебоксаров». Чуваш халык уены.</td></tr>
<tr><th>Үткәрү вакыты</th><th>Тема<br>Сүзлек</th><th>Эш төрләре</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td>Февраль<br>I атна<br>1.1<br>Төп белем бирү эшчәнлеге</td><td>Тема:<br>Безнең дуслар.<br><br>Сүзлек:<br>тавык<br>әтәч</td><td>Уен ситуациясе «Бу нәрсә?». Аудио (31 нче кисәк)<br>— Ребята, к нам из цирка пришли домашние птицы. Давайте с ними познакомимся (хатын-кыз тавышы, кыска пауза).<br>Тәрбияче әтәчне күрсәтә: Бу әтәч. Бу әтәч. Әтәч.<br>Бергә: Әтәч. Әтәч. Әтәч.<br>Тәрбияче тавыкны күрсәтә: Бу тавык. Бу тавык. Тавык.<br>Балалар: Тавык. Тавык. Тавык.<br>«Әтәч», «Тавык» сүзләре яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.<br>Тәрбияче: Әтәч нинди?<br>Балалар: Әтәч матур, зур.<br>Тәрбияче: Тавык нинди?<br>Балалар: Тавык матур, кечкенә.<br>Сүзле уен «Ватык телефон».<br>Балаларга «әтәч зур», «тавык кечкенә» сүзтезмәләре әйтелә.<br>Уен ситуациясе «Әйткәнне үтә».<br>Балаларга әтәч, тавык битлекләре таратыла. Тәрбияче һәр баладан сорый:<br>— Син кем?<br>Бала: Мин әтәч (тавык).<br>Тәрбияче: Әтәч (тавык), кил монда. Син нинди әтәч (тавык)?<br>Бала: Мин зур (кечкенә), матур әтәч (тавык).<br>Тәрбияче: Әтәч (тавык), сикер (аша, эч, йөгер, уйна, утыр).<br>Бала команданы үти.<br>Тәрбияче: Әтәч, нишлисең?</td><td>Курчак театры атрибутлары: тавык, әтәч.<br>Битлекләре: әтәч, тавык.<br>Уенчыклар: тавык, әтәч.<br>Аудиоязма 31–32.</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Бала: Мин сикерәм (ашыйм, эчәм, йөгерәм, уйныйм, утырам).<br>**Ситуатив күнегү.**<br>Тәрбияче: Петухи и курицы птицы необыкновенные, они умеют рассказывать о том, что делают. Петушок прыгает, как он скажет об этом?<br>Бала: Мин әтәч. Мин сикерәм (йөгерәм, ашыйм, эчәм, утырам, уйныйм).<br>**Җырлы-биюле уен «Әйдәгез биибез».** *Аудио (32 нче кисәк)*<br>1) Бар монда зур әтәч,<br>Зур әтәч, матур әтәч.<br>Әтәч, әтәч, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле.<br>Әтәч, әтәч, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле.<br>2) Бар кечкенә тавык,<br>Кечкенә, матур тавык.<br>Тавык, тавык, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле.<br>Тавык, тавык, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. | |
| **Февраль**<br>**I атна**<br>**1.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Үрдәк дусларын тапты.<br><br>*Сүзлек:*<br>үрдәк | **Уен ситуациясе «Кунак килә».** *Аудио (33 нче кисәк)*<br>**Ишек шакыган тавыш** *(кыска пауза).*<br>Балалар: Кем анда?<br>Үрдәк: Бак-бак, мин.<br>Балалар: Кил монда.<br>**Ишек ачылган тавыш** *(кыска пауза).*<br>Үрдәк: Исәнмесез!<br>Балалар: Исәнмесез! Син кем?<br>Үрдәк: Мин үрдәк. Мин үрдәк. Үрдәк.<br>***«Үрдәк»* сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.**<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».**<br>Балаларга «зур үрдәк», «матур үрдәк» сүзтезмәләре әйтелә.<br>**Уен ситуациясе «Дусларны сыйлыйбыз».** *Аудио (34 нче кисәк)*<br>Үрдәк: Бак-бак. Хозяин цирка ищет своих зверей, птиц. Отправил меня за ними.<br>— Утка долго шла, проголодалась, давайте угостим. Үрдәк, кил монда, утыр. Мә ботка аша *(хатын-кыз тавышы).*<br>Үрдәк: Бак-бак. Рәхмәт, ботка тәмле.<br>— Давайте позовём зверей, птиц и угостим их тоже *(хатын-кыз тавышы).*<br>**Үрдәк, тычкан, бүре, әтәч, тавык ролендәге балаларга битлекләр таратыла. Башка балалар аларны чакырып сыйлыйлар.** | Курчак театры атрибуты: үрдәк.<br>Битлекләр: үрдәк, тычкан, бүре, әтәч, тавык.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 33–34. |

<table>
<tr><td></td><td></td><td>Оля: Бүре, кил монда, утыр. Мә, ипи аша.<br>Бүре: Рәхмәт, ипи тәмле.<br>Диалог шул үрнәктә дәвам итә.<br>Ситуатив күнегү «Макта».<br>Тәрбияче: Ребята, хозяин цирка ждёт своих зверей и птиц. Но перед прощанием их надо похвалить. Как вы это сделаете? Оля, похвали утку.<br>Оля: Үрдәк, син матур, әйбәт, зур, чиста. Сау бул, үрдәк!<br>Балалар җәнлекләрне, кошларны мактап саубуллашалар.<br>Дәфтәрдә эш. 10 нчы бирем «В цирке».</td><td></td></tr>
<tr><th>Үткәрү вакыты</th><th>Тема<br>Сүзлек</th><th>Эш төрләре</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td rowspan="4">Февраль<br>I атна<br>1.3<br>(режим вакыты)</td><td rowspan="4">Тема:<br>Безнең дуслар.<br><br>Сүзлек:<br>тавык<br>әтәч</td><td>Режим вакытында уен эшчәнлеге<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)</td><td rowspan="2"></td></tr>
<tr><td>Уен ситуациясе «Бу нәрсә? Нинди?»<br>Дидактик уен «Бу кем? Нишли?»<br>Җырлы-биюле уен «Әйдәгез биибез». Аудио (34–35 нче кисәкләр)<br>Хәрәкәтле уен «Выполни команду».<br>Сүзле (үстерешле) уен «Хыялый сәяхәт» (күзаллау, фантазия, хәтер сәләтләрен үстерү. Тактада гаилә әгъзалары, төрле җәнлек, кош, транспорт рәсемнәре эленгән. Балалар шуларны сайлап сөйлиләр. Үрнәк: Мин тавык. Мин кара, матур, чиста... тавык. Мин автобуста... барам.)<br>Уен ситуациясе «Әйткәнне үтә».<br>Составление описательных загадок «Представьте себе» (отгадывание задуманного персонажа по имитационным движениям).</td></tr>
<tr><td>Өстәмә материал<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)</td><td rowspan="2">М.Ф. Кашапова «Иң татлы тел – туган тел» (337 б.).</td></tr>
<tr><td>М.Җәлил әсәрләре буенча «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» интеллектуаль уены<br>«Үз-үземә режиссёр». (Җәнлекләр турында балалар мөстәкыйль рәвештә әкият уйлап чыгаралар.)<br>Курчак театры «Сәгать» (М.Җәлил әсәре буенча).<br>«Башмак киеп бию».</td></tr>
<tr><td>Февраль<br>II атна<br>2.1<br>Төп белем бирү эшчәнлеге</td><td>Тема:<br>Акбай чана шуа.<br><br>Сүзлек:<br>чана<br>шуа</td><td>Уен ситуациясе «Тауда».<br>Когда зверята возвращались в цирк, увидели большую красивую горку. На горке Акбай катается на санках.<br>Бергә: Исәнме, Акбай! Хәлләр ничек?<br>Акбай: Әйбәт.<br>Бергә (чанага күрсәтеп): Бу нәрсә?<br>Акбай: Санки — чана. Чана.</td><td>Уенчык Акбай.<br>Уенчык чана.<br>Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, керпе чана шуа, әтәч чана шуа.</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Аудиоязма тыңлау.** *Аудио (35 нче кисәк)*<br>— Слушайте, как будет санки по-татарски (*ир-ат тавышы, кыска пауза).*<br>— Бу чана *(ир-ат тавышы, озын пауза, тәрбияче куянның чанасын күрсәтә).*<br>— Бу чана *(кыска пауза).* Повторите *(кыска пауза).* Бу чана *(ир-ат тавышы, озын пауза, балалар кабатлый).*<br>— Бу чана.<br>— Бу чана *(ир-ат тавышы, озын пауза, балалар кабатлый).*<br>— Бу чана.<br>— Слушайте *(кыска пауза).* Заяц катается на санках *(ир-ат тавышы, кыска пауза).*<br>— Куян чана шуа *(кыска пауза).* Куян чана шуа *(ир-ат тавышы, тәрбияче куянны чанасына утыртып шудыра).*<br>**Сүзле уен «Нишли?»**<br>Уен сюжетлы рәсемнәр (куян чана шуа, аю чана шуа, бүре чана шуа, керпе чана шуа, әтәч чана шуа, төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа) ярдәмендә оештырыла.<br>Акбай: Ребята, из цирка звери и птицы прислали вам свои фотографии. Я вам подарю фотографии в том случае, если вы правильно ответите на вопрос: «Бу кем?», «Нишли?».<br>Акбай: Бу кем? (Төлке, куян, аю, бүре, керпе, әтәч, тавык, үрдәк.)<br>Коля: Бу төлке (куян, аю, бүре, керпе, әтәч, тавык, үрдәк).<br>Акбай: Төлке (куян, аю, бүре, керпе, әтәч, тавык, үрдәк) нишли?<br>Коля: Төлке (куян, аю, бүре, керпе, әтәч, тавык, үрдәк) чана шуа.<br>**Уен шул үрнәктә дәвам итә.**<br>**«Чана шуа» пиктограммасы белән таныштыру.**<br>**Үстерешле диалог «Бу нәрсә? Нишли?»**<br>**Бала белән бала арасында диалог.**<br>Коля: Бу нәрсә? *(Төлкегә күрсәтеп.)*<br>Оля: Бу төлке.<br>Коля: Төлке нишли?<br>Оля: Төлке чана шуа.<br>*(Шул үрнәктә һәр бала сюжетлы рәсемнәр буенча үзара диалог оештыра.)*<br>**Аудиоязмадан җыр тыңлау, җырлау «Чана шуа».** *Аудио (36 нчы кисәк)*<br>Куян нишли? Чана шуа.<br>Төлке нишли? Чана шуа.<br>Бүре нишли? Чана шуа.<br>Аю нишли? Чана шуа.<br>**Дәфтәрдә эш. 11 нче бирем «На горке».** | Төлке чана шуа, үрдәк чана шуа, тавык чана шуа.<br>«Чана шуа» пиктограммасы.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 35–36. |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Февраль**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Чана шуам.<br><br>*Сүзлек:*<br>шуам | **Уен ситуациясе «Нишлисең?»**<br>**Акбай белән Мияу, җырлый-җырлый, чана тартып керәләр.** *Аудио (37 нче кисәк)*<br>Мин Акбай, мин Акбай,<br>Зур Акбай, матур Акбай *(малай тавышы).*<br>Мин Мияу, мин Мияу,<br>Зур Мияу, матур Мияу *(кыз тавышы).*<br>**Аудиоязма тыңлау.** *Аудио (38 нче кисәк)*<br>**Акбай белән Мияу сөйләшә. Тәрбияче хәрәкәтләр белән күрсәтеп тора.**<br>Мияу: Акбай, бу нәрсә? *(Хатын-кыз тавышы.)*<br>Акбай: Бу чана *(ир-ат тавышы).*<br>Мияу: Чана нинди? *(Хатын-кыз тавышы.)*<br>Акбай: Чана зур, кызыл *(ир-ат тавышы).*<br>**Чана шуган тавыш ишетелә.**<br>Мияу: Акбай, нишлисең? *(Хатын-кыз тавышы.)*<br>Акбай: Мин чана шуам. Мияу, кил монда. Утыр *(ир-ат тавышы).*<br>Мияу: Мин чана шуам *(хатын-кыз тавышы).*<br>**Уен ситуациясе «Шуа – шуам».**<br>Тәрбияче: Мияу и Акбай катаются на санках. Ребята, как вы скажете, что:<br>а) Акбай катается на санках (Акбай чана шуа);<br>ә) Мияу катается на санках (Мияу чана шуа).<br>Тәрбияче: Акбай, ты катаешься на санках, как ты скажешь об этом?<br>Акбай: Мин чана шуам.<br>Тәрбияче: Оля, ты катаешься на санках, как ты скажешь об этом?<br>Оля: Мин чана шуам.<br>*(Шул рәвешле һәр баладан сорау-җавап алына.)*<br>**Үстерешле диалог «Син нишлисең?»**<br>**Бала белән бала арасында диалог.**<br>**Балаларга схема-пиктограммалар таратыла.**<br>**Эчәм, ашыйм, утырам, уйныйм, барам, йөгерәм, сикерәм, йоклыйм, шуам.**<br>**Бала белән бала арасында диалог.**<br>Коля: Оля, син нишлисең?<br>Оля: Мин утырам. Син нишлисең?<br>Коля: Мин уйныйм.<br>*(Диалогта һәр бала катнаша.)*<br>**Дәфтәрдә эш. 12 нче бирем «Что ты делаешь?»** *(Пиктограммалар белән.)* | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Схема-пиктограммалар: эчәм, ашыйм, утырам, уйныйм, барам, йөгерәм, сикерәм, йоклыйм, шуам.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 37–38. |

<table>
<tr>
<td rowspan="4">Февраль<br>II атна<br>2.3<br>(режим вакыты)</td>
<td rowspan="4">Тема:<br>Циркта.<br><br>Сүзлек:<br>тавык<br>әтәч<br>үрдәк</td>
<td>Режим вакытында уен эшчәнлеге<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)</td>
<td rowspan="2"></td>
</tr>
<tr>
<td>Уен ситуациясе «Әбигә ярдәм ит» (үрдәк югалган, рәсемнәрдән табып бирәләр, аңлаталар).<br>Өстәл өсте уены «Парлы рәсемнәр».<br>«Мәйданчыгыбыз серләре» (балалар элемент буенча кар астында яшеренгән предметны табып, исемен әйтәләр, ничек йөрүен хәрәкәттә күрсәтәләр).<br>Уен ситуациясе «Дусларны сыйлыйбыз».<br>Дәфтәрдә эш. 10 нчы бирем «Циркта» (ИКТ-уен).<br>Дидактик уен «Парын тап».</td>
</tr>
<tr>
<td>Өстәмә материал<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)</td>
<td rowspan="2">Анимацион сюжет (30 тема).<br>М.Ф. Кашапова «Иң татлы тел – туган тел» (337 б.). К.В. Закирова. «Балачак аланы» (474, 480 б.).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (41 с.).<br>Л.Батыр-Болгари. Диск.</td>
</tr>
<tr>
<td>«Циркта» анимацион сюжетын карау (эчтәлеге буенча әңгәмә).<br>Өстәл уены «Циркта».<br>Җырлы-биюле уен «Чума үрдәк, чума каз», «Утыр, утыр, Мәликә».<br>Уку Б.Рахмат «Петушок».<br>Уку Н.Мадьяров «Әйтә үрдәк», «Үрдәк белән сөйләшү».<br>А.Алиш «Болтливая утка» мультфильмын карау.<br>«Без үрдәкләр» җырын тыңлау, сәхнәләштерү.</td>
</tr>
<tr>
<td>Февраль<br>III атна<br>3.1<br>Төп белем бирү эшчәнлеге</td>
<td>Тема:<br>Әйдә бие!<br><br>Сүзлек:<br>бие<br>бии<br>әйдә</td>
<td>Уен ситуциясе: «Бие!» Аудио (39 нчы кисәк)<br>«Зиләйлүк» татар халык көе ишетелә.<br>— Ребята, слушайте, какая красивая, весёлая плясовая мелодия «Зиләйлүк». Так и хочется поплясать. Давайте вместе попросим: Акбай, танцуй. Акбай, бие. Мияу, танцуй. Мияу, бие.<br>Бергә: Акбай, бие, бие (Акбай бии).<br>Мияу, бие, бие (Мияу бии).<br>Татар халык уены «Түбәтәй». Аудио (40 нчы кисәк)<br>«Зиләйлүк» татар халык көе.<br>Балалар түгәрәктә бию көенә бииләр, түбәтәйне кулдан-кулга җибәрәләр. Музыка туктаганда түбәтәй кем кулында кала, шул балага биергә тәкъдим ителә:<br>— Оля, бие, бие. (Оля уртага чыгып бии.)<br>— Коля, бие, бие. (Коля уртага чыгып бии.)<br>Уен шулай дәвам итә.<br>Ситуатив күнегү «Нишли?»<br>Балаларга куян, аю, бүре, төлке, керпе, әтәч, тавык, үрдәк битлекләре тәкъдим ителә.</td>
<td>Уенчык Акбай, Мияу. Түбәтәй.<br>Битлекләр: куян, аю, бүре, төлке, керпе, әтәч, тавык, үрдәк.<br>«Бии» пиктограммасы.<br>Аудиоязма 39–40.</td>
</tr>
<tr>
<td></td><td></td><td></td><td></td>
</tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Тәрбияче: Ребята, представьте себе, что вы «заводные игрушки». «Заведите» игрушку и предложите прыгать.<br>а) Бергә: Куян, әйдә сикер! *(Куян битлеге кигән бала сикерә.)*<br>Тәрбияче: Куян нишли?<br>Бергә: Куян сикерә.<br>б) Бергә: Аю, кил монда!<br>Тәрбияче: «Заведите» игрушку и предложите танцевать.<br>Бергә: Аю, әйдә бие. *(Аю битлеге кигән бала бии.)*<br>Тәрбияче: Аю нишли?<br>Бергә: Аю бии.<br>*Шул үрнәктә керпе, тычкан, бүре, төлке, әтәч, тавык, үрдәк битлекләре кигән балалар чакырыла. Аларга «утыр», «йөгер», «йокла», «ю», «аша», «уйна», «эч» дигән хәрәкәтләрне кабатларга тәкъдим ителә.*<br>**«Бии» пиктограммасы белән таныштыру.**<br>**Ирекле бию «Без биибез».**<br>Тәрбияче: Ребята, сегодня мы с вами очень хорошо занимались, весело играли, давайте вместе станцуем. Пригласите друг друга, предложите танцевать:<br>— Оля (Маша, Таня), кил, бие!<br>— Коля (Саша, Ваня), кил, бие!<br>*Тәрбияче үрнәгендә балалар бер-берсен биергә чакыралар. Бергә бииләр.* | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема<br>Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Февраль<br>III атна<br>3.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Без биибез.<br><br>*Сүзлек:*<br>биим | **Уен ситуациясе «Без биибез».** *Аудио (41 нче кисәк)*<br>**Татар халык бию көе ишетелә. Акбай белән Мияу бииләр.**<br>Тәрбияче: Акбай, син нишлисең? *(Акбай ишетми, һаман биеп тора.)*<br>Ребята, Акбай не слышит. Давайте вместе спросим: Акбай, нишлисең?<br>Бергә: Акбай, син нишлисең?<br>Акбай: Мин биим. Мин биим *(Акбай бии).*<br>Бергә: Мияу, син нишлисең?<br>Мияу: Мин биим. Мин биим *(Мияу бии).*<br>Акбай: Оля, син нишлисең?<br>Оля: Мин утырам.<br>Акбай: Оля, әйдә бие! *(Оля уртага чыга, бии.)*<br>Мияу: Коля, син нишлисең?<br>Коля: Мин утырам.<br>Мияу: Коля, әйдә бие! *(Коля чыга, бии.)*<br>Акбай: Ребята, приглашайте друг друга плясать.<br>— Оля (Саша, Таня, Ваня...), кил, бие!<br>Акбай: Оля, син нишлисең? | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Хәрәкәт белдерүче пиктограммалар: сикер, йөгер, уйна, утыр, бие.<br>Такта, мольберт.<br>Сюжетлы рәсемнәр: Куян сикерә. Аю йоклый. Песи сөт эчә. Төлке бии. Керпе йоклый. Бүре йөгерә. Эт ашый. Тычкан чана шуа. Бүре утыра.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 41. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Саша: Мин бииم.<br>Акбай: Саша, син нишлисең?<br>Саша: Мин бииm.<br>**Үстерешле диалог «Син нишлисең?**<br>**Бала белән бала арасында диалог.**<br>*Балаларда төрле хәрәкәтне белдергән пиктограммалар: сикер, йөгер, уйна, утыр, бие.*<br>Коля: Оля, син нишлисең?<br>Оля *(пиктограммага карап):* Мин сикерәм. Коля, син нишлисең?<br>Коля *(пиктограммага карап):* Мин бииm. Саша, син нишлисең?<br>**Уен шулай дәвам итә.**<br>**Уен «Нишли, бел?!» (***Тактада яки мольбертта хәрәкәтне белдерүче күрсәтмә рәсемнәр: Куян сикерә. Аю йоклый. Песи сөт эчә. Төлке бии. Керпе йоклый. Бүре йөгерә. Эт ашый. Тычкан чана шуа. Бүре утыра. Бер бала рәсемне яшереп, сорый.)*<br>а) Коля: Куян нишли?<br>Балалар: Куян сикерә?<br>Коля: Юк.<br>Балалар: Куян йоклый?<br>Коля: Юк.<br>Балалар: Куян бии?<br>Коля: Әйе, куян бии.<br>ә) Оля: Төлке нишли?<br>Балалар: Төлке уйный?<br>Оля: Юк.<br>Балалар: Төлке йөгерә?<br>Оля: Юк.<br>Балалар: Төлке бии?<br>Оля: Әйе, төлке бии.<br>*Уен шулай дәвам итә.*<br>**Дәфтәрдә эш. 13 нче бирем «Кем нишли?»** *(Пиктограммалар яисә сюжетлы рәсемнәр белән.)* | |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Февраль**<br>**III атна**<br>**3.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Шаян кошлар.<br><br>*Сүзлек:*<br>чана<br>шуа<br>шуам | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **Сүзле уен «Нишли?»** *(Пиктограммалар белән.)*<br>**Үстерешле диалог «Бу нәрсә? Нишли?»**<br>**Хәрәкәтле уен «Син нишлисең?»**<br>**Сүзле уен «Яшерелгән әйберне тап»** *(тәрбияче тасвирлау бирә, бала шул аңлатма буенча әйтеп бирә, бергә эзләп табалар, дөреслеген тикшерәләр).*<br>**«Шаян кошлар» анимацион сюжеты буенча персонажларның контурлы рәсемнәрен буяу.** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Анимацион сюжет (33 тема).<br>К.В. Закирова. «Балачак аланы» (515 б.).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (135 с.). |
| | | **«Сертотмас үрдәк» әкиятен сәхнәләштерү.**<br>**«Шаян кошлар» анимацион сюжетын карау** *(эчтәлеге буенча әңгәмә).*<br>**«Үз-үзеңә режиссёр».** *(«Сертотмас үрдәк» әкиятенә таянып.)*<br>**Уку Г.Тукай «Белый дед».**<br>**«Белый дед» мультфильмын карау.**<br>**Уку Ә.Кари «Кыш бабай».** | |
| **Февраль**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Мияуның бүлмәсен бизибез.<br><br>*Сүзлек:*<br>ак<br>кара | **Уен ситуациясе «Төсле шарлар сайла».** *Аудио (42 нче кисәк)*<br>Акбай: Скоро у Мияу день рождения. Я не приготовил ей подарок. А знаете почему? Зашёл в магазин, где продавались огромные воздушные шары. Но забыл, как назвать цвета по-татарски и стал показывать пальцами. Продавцы не захотели со мной разговаривать, с таким невежливым. Чтобы такого не повторилось, помогите мне вспомнить цвета по-татарски.<br>*Балаларда төрле төстәге шар рәсемнәре: яшел, сары, кызыл, зәңгәр, ак, кара. Балалар, төсләрне әйтеп, тактага төрле төстәге шар рәсемнәрен беркетәләр. Ә Акбай ак, кара шар рәсемнәрен беркетә.*<br>Акбай: Белый шар — ак шар. Чёрный шар — кара шар.<br>***«Ак», «кара»* сүзләре яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.**<br>**Дидактик уен «Нинди шар юк?»**<br>**Сүзле уен «Нинди шар яратам».**<br>Тәрбияче: Оля, кил монда.<br>*(Оля үзенә ошаган яшел шарны тактада күрсәтә.)*<br>Акбай: Оля кызыл шар ярата?<br>Оля: Юк.<br>Акбай: Оля яшел шар ярата?<br>Оля: Әйе, мин яшел шар яратам. | Уенчык Акбай.<br>Төсле (кызыл, яшел, зәңгәр, сары, ак, кара) шарлар, 1–10 кадәр санда.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 42–44. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | *Уен шул рәвешле бала белән бала арасында дәвам итә.*<br>**Уен ситуациясе «Шар бир әле».**<br>Акбай: Подойдите и спросите у меня шар такого цвета, который вам нравится.<br>Оля: Акбай, ак шар бир әле.<br>Акбай: Мә ак шар.<br>Оля: Рәхмәт.<br>Акбай: Как скажешь, что тебе нравится белый шар?<br>Оля: Мин ак шар яратам.<br>*Бала белән бала арасында диалог дәвам итә.*<br>**Уен «Ничә шар?»**<br>*Балалар шарларны (1–10 га кадәр) саныйлар.*<br>**Уен ситуациясе «Бүлмәне бизибез».**<br>*Акбай ярдәмендә Мияуның бүлмәсен төсле шарлар белән бизиләр.*<br>**Сүзле-хәрәкәтле уен «Әгәр сиңа ошый икән, шулай ит».**<br>*Акбай хәрәкәтләр күрсәтә. Балалар хәрәкәтләрне кабатлап күрсәтәләр, әйтәләр. Аудио (43 нче кисәк)*<br>Акбай: Если нравится тебе, то делай так. — Әгәр сиңа ошый икән, шулай ит (бии).<br>Балалар: Акбай, син нишлисең?<br>Акбай: Мин биим (сикерәм, йөгерәм, туп уйныйм, утырам, биим).<br>*Шул үрнәктә уен дәвам итә.*<br>**Аудиоязма тыңлау.** *Аудио (44 нче кисәк)*<br>Акбай: Я думаю, что день рождения Мияу будет интересным, если мы для неё выучим песню.<br>**Җыр «Туган көн».**<br>Мияуның туган көненә<br>Без пешердек ак ипи.<br>Менә шундый ипи зур,<br>Менә шундый кечкенә.<br>Менә шундый тәмле,<br>Менә шундый баллы.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Әйе шул, ипи тәмле.<br>**Дәфтәрдә эш. 14 нче бирем «Шары ко дню рождения».** | |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Февраль**<br>**IV атна**<br>**4.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Туган көнгә бүләк әзерлибез.<br><br>*Сүзлек:*<br>җырла<br>җырлыйм | **Үстерешле диалог «Кибет».**<br>Акбай: Чтобы купить подарки на день рождения Мияу, вспомним названия игрушек и вежливые слова.<br>*Кибеттәге төрле зурлыктагы, төстәге, сандагы уенчыклар. Мәсәлән: ике аю, берсе — ак, икенчесе кара төстә.*<br>**Акбай белән бала арасында үрнәк диалог:**<br>Акбай (кибетче): Исәнме, Оля!<br>Оля: Исәнме, Акбай!<br>Акбай: Хәлләр ничек?<br>Оля: Әйбәт.<br>Акбай: Оля, нәрсә кирәк?<br>Оля: Куян кирәк.<br>Акбай: Нинди куян?<br>Оля: Ак (...), матур куян.<br>Акбай: Ничә куян?<br>Оля: Ике куян.<br>Акбай: Мә ике куян.<br>Оля: Рәхмәт! Сау бул, Акбай!<br>Акбай: Сау бул!<br>*Уен уенчыклар беткәнче дәвам итә.*<br>**Үстерешле уен «Уенчыгың турында сөйлә».**<br>Акбай: Мы не просто подарим Мияу игрушки, а ещё и расскажем о них.<br>Оля: Бу куян. Куян ак, матур, әйбәт. Куян сикерә.<br>Коля: Бу песи. Песи сары. Песи сөт эчә. Песи утыра.<br>Акбай: Ребята, давайте все игрушки положим в красивую коробку. А когда пойдём на день рождения, подарим их Мияу.<br>**Уен: «Җырлыйм».** *Аудио (45 нче кисәк)*<br>Акбай: На день рождения Мияу я приготовил в подарок песню.<br>Бергә: Акбай, җырла!<br>Акбай: Я люблю петь! Я пою — мин җырлыйм.<br>Акбай: Мин җырлыйм, җырлыйм (лә-лә-лә).<br>Бергә: Акбай, син нишлисең?<br>Акбай: Мин җырлыйм. А вы любите петь?<br>Тәрбияче: Оля, җырла!<br>Оля: Мин җырлыйм, җырлыйм (лә-лә-лә).<br>**«Җырла» сүзе балалар тарафыннан әйттерелә.** | Төрле зурлыктагы, төстәге, сандагы уенчыклар.<br>Аудиоязма 45–46. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Тәрбияче: Коля, ты поёшь. Как ты скажешь об этом?<br>Коля: Мин җырлыйм.<br>**Аудиоязма тыңлау, җырлау.** *Аудио (46 нчы кисәк)*<br>1) Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>2) Мин биим, биим, биим,<br>Мин матур биим, биим.<br>Мин биим, биим, биим,<br>Мин матур биим, биим.<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,<br>Мин матур биим, биим.<br>Акбай: Вот какую красивую песенку спели, Мияу обрадуется. | |
| **Февраль**<br>**IV атна**<br>**4.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Урманда зур концерт.<br><br>*Сүзлек:*<br>бие<br>бии<br>әйдә<br>биим | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **Ситуатив күнегү «Нишли?»** *(маскалар белән).*<br>**Уен ситуациясе «Җанлы рәсемнәр»** *(тавык, үрдәк, әтәч, аю, куян, эт, песи, тычкан чана шуа, конструкцияләрен ныгыту),* **шулай ук «Гаилә» темасын кертергә мөмкин.**<br>**Татар халык уены «Түбәтәй».**<br>**Хәрәкәтле уен «Поезд»** *(2–3 бала, кулга-кул тотынышып, таудан шуып төшәләр).*<br>**«Чана шуа», «чана шу», «чана шуам» сүзләрен ныгыту.**<br>**Үстерешле диалог «Син нишлисең?»**<br>**Дәфтәрдә эш. 13 нче бирем: «Кем нишли?» (ИКТ-уен).**<br>**«Әтиләргә концерт» уены.**<br>**«Командир» уены.** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Анимацион сюжет (36 тема).<br>К.В. Закирова «Бала-чак аланы» (509 б.).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (211 с.). |
| | | **Анимацион сюжет карау «Урманда зур концерт»** *(эчтәлеге буенча әңгәмә).*<br>**Ковробук-уен «Җәнлекләр концерт куя».**<br>**Театральләштерелгән уен ситуациясе «Урманда зур концерт»** *(рольләргә бүленеп, балалар уйный).*<br>**Уку Р.Бәшәр «Курай».**<br>**Уку Ш.Галиев «Кто играет на курае?»**<br>**Сәхнәләштерү М.Җәлил «Карак песи».** | |

| Үткәрү вакыты | Тема Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Март**<br>**I атна**<br>**1.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Мияуның туган көне.<br><br>*Сүзлек:*<br>җырлыйбыз<br>зур рәхмәт | **Уен ситуациясе «Мияуда кунакта».** *(Акбай белән балалар Мияуга кунакка киләләр.)*<br>Бергә: Исәнме, Мияу!<br>Мияу: Исәнмесез, балалар!<br>Бергә: Хәлләр ничек, Мияу?<br>Мияу: Әйбәт. Рәхмәт.<br>Бергә: С днём рождения, Мияу. Туган көнең белән!<br>Тәрбияче: Давайте на день рождения Мияу споём песню «Каравай» — «Туган көн».<br>Акбай: Әйдәгез җырлыйбыз!<br>**Аудиоязмага кушылып җырлау.** *Аудио (47 нче кисәк)*<br>**Җыр «Туган көн».**<br>Мияуның туган көненә<br>Без пешердек ак ипи.<br>Менә шундый ипи зур,<br>Менә шундый кечкенә.<br>Менә шундый тәмле,<br>Менә шундый баллы.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Әйе шул, ипи тәмле.<br>Мияу: Зур рәхмәт!<br>Акбай: Ребята, видите, Мияу не просто говорит спасибо, а «большое спасибо» — «зур рәхмәт».<br>Мияу: Зур рәхмәт!<br>Акбай: Попросите Мияу, чтобы она станцевала.<br>Бергә: Мияу, әйдә бие!<br>*Мияу татар бию көенә бии.*<br>Бергә: Мияу матур бии.<br>Мияу: Зур рәхмәт!<br>**Үстерешле диалог «Минем бүләгем».** *(Уенчыклар салынган тартма тора.)*<br>Акбай: Ребята, а теперь подарим игрушки Мияу. Сначала вспомним, кто какую игрушку купил.<br>*(Балалар, чиратлашып, үзләренең уенчыкларын алалар, алар турында сөйләп, Мияуга бүләк итәләр.)*<br>Оля: Бу аю. Аю зур (матур, чиста, ак, кара). Аю уйный (бии, җырлый). Мә, Мияу, аю.<br>Мияу: Зур рәхмәт! | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 47. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | *(Шул үрнәктә һәр бала үзенең уенчыгын Мияуга бүләк итә. Уйный, бии, утыра, сикерә, йоклый, шуа, йөгерә, ашый, эчә һәм җырлый, дигәч, хәрәкәтләр белән күрсәтәләр. Мәсәлән: Мияу җырлый: «Мяу-мяу». Эт җырлый: «Һау-һау».)*<br>Мияу: Зур рәхмәт! Приходите ещё. Сау булыгыз!<br>Бергә: Сау булыгыз!<br>**Дәфтәрдә эш. 15 нче бирем «День рождения».** | |
| **Март**<br>**I атна**<br>**1.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Туган көн табынында.<br><br>*Сүзлек:*<br>зур рәхмәт | **Уен ситуациясе «Табышмакларга җавап тап».** *(Уенны сюжетлы рәсемнәргә таянып үткәрергә була.) Аудио (48 нче кисәк)*<br>— День рождения продолжается *(хатын-кыз тавышы).*<br>Мияу: Я вам тоже приготовила сюрприз. Отгадайте мои загадки.<br>1) Мин зур, матур, әйбәт. Мин йөгерәм, сикерәм, утырам, җырлыйм: «Тяф-тяф». Бел *(ир-ат тавышы, озын пауза).*<br>— Төлке *(хатын-кыз тавышы).*<br>2) Мин кара. Мин кечкенә, матур, әйбәт. Мин йөгерәм, сикерәм, биим, ашыйм, җырлыйм: «Чи-чи-чи». Бел *(ир-ат тавышы, озын пауза).*<br>— Тычкан *(хатын-кыз тавышы).*<br>3) Мин кызыл. Мин зур, матур, әйбәт. Мин ипи ашыйм, су эчәм, биим, җырлыйм: «Кикрикүк». Бел *(ир-ат тавышы, озын пауза).*<br>— Әтәч *(хатын-кыз тавышы).*<br>4) Мин ак. Мин кечкенә, матур, әйбәт. Мин ипи ашыйм, йөгерәм, җырлыйм: «Ко-ко-ко». Бел *(ир-ат тавышы, озын пауза).*<br>— Тавык *(хатын-кыз тавышы).*<br>Мияу: Зур рәхмәт, балалар!<br>**Уен ситуациясе «Туган көн табынында».** *(Уен муляжлар белән үткәрелә.) Аудио (49 нчы кисәк)*<br>Мияу: Әйдәгез, балалар, утырыгыз. Вы сидите за волшебным праздничным столом, будьте вежливы, угощайте друг друга.<br>Мияу: Нәрсә кирәк?<br>Акбай: Алма кирәк.<br>Мияу: Нинди алма?<br>Акбай: Яшел (кызыл, сары), зур (кечкенә), тәмле алма.<br>Мияу: Мә яшел алма.<br>Акбай: Зур рәхмәт!<br>Мияу: Акбай, син нишлисең?<br>Акбай: Мин алма ашыйм.<br>Мияу: Алма тәмле(ме)?<br>Акбай: Әйе, алма тәмле. Мин алма яратам. | Сюжетлы рәсемнәр: төлке, тычкан, әтәч, тавык.<br>Ашамлык муляжлары.<br>Аудиоязма 45, 48–49. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Үстерешле диалог «Сыйланабыз».** *(Алдагы эшчәнлек үрнәгендә бала белән бала арасында диалог дәвам итә.)*<br>а) Оля: Коля, нәрсә кирәк?<br>Коля: Чәй (кофе, сок, сөт, бәрәңге, пицца...) кирәк.<br>Оля: Мә чәй (кофе, сок, сөт, бәрәңге, пицца...)<br>Коля: Чәй (кофе, сок, сөт, бәрәңге, пицца...) тәмле. Зур рәхмәт.<br>ә) Оля: Син нишлисең? *(«Ашыйм», «эчәм» кабатлана.)*<br>Коля: Мин чәкчәк (өчпочмак) ашыйм.<br>Оля: Чәкчәк (өчпочмак) тәмле(ме)?<br>Коля: Әйе, тәмле, баллы.<br>б) Оля: Коля, мә алма. *(«Яратам» кабатлана.)*<br>Коля: Мин алма яратам.<br>Бергә *(соңыннан):* Мияу, зур рәхмәт!<br>**Аудиоязма тыңлау, җырлау.** *Аудио (45 нче кисәк)*<br>1) Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә.<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>2) Мин биим, биим, биим,<br>Мин матур биим, биим.<br>Мин биим, биим, биим,<br>Мин матур биим, биим.<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә.<br>Мин матур биим, биим.<br>**Күмәк бию.** | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема<br>Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Март<br>I атна<br>1.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Акбай туган көнгә барырга әзерләнә.<br><br>*Сүзлек:*<br>ак<br>кара<br>җырла<br>җырлыйм | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Үстерешле диалог «Кибет». Уен «Җырлыйм».**<br>**Сүзле-хәрәкәтле уен «Әгәр сиңа ошый икән, кабатла!»**<br>**Җырлы уен «Ак калач».**<br>**Аз хәрәкәтле уен «Зур туп»** *(рус халык уены).*<br>**Үстерешле диалог «Уенчыгың турында сөйлә».**<br>**Үстерешле уен «Хәрәкәтне белдерүче сүзләрне тап»** *(ю, аша, эч, утыр, уйна, җырла, шу).* | К.В. Закирова «Балачак — уйнап-көлеп үсәр чак» (127 б.). |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Анимацион сюжет (39 тема). |
| | | **Анимацион сюжет карау «Акбай туган көнгә барырга әзерләнә» — «Акбай собирается на день рождения»** *(беседа по содержанию).*<br>**Сюжет буенча рәсемнәр ясау.**<br>**Хәрәкәтле уен «Ак калач», «Бүген кемнең туган көне?»** | |
| **Март**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Күңелле сәяхәт.<br><br>*Сүзлек:*<br>китап укый | **Уен ситуациясе «Сәяхәткә әзерләнәбез».**<br>Акбай: Будем готовиться к путешествию в волшебную страну «Школа». Мы берём того, кто сможет ответить на вопросы Мияу. Будьте внимательны!<br>*Мияу балаларга хәрәкәтне белдерүче рәсемнәр күрсәтеп сорый.*<br>Мияу: Оля, бу нәрсә?<br>Оля: Бу куян.<br>Мияу: Куян нишли?<br>Оля: Куян сикерә (ашый, эчә, йөгерә, утыра, йоклый, бит юа, чана шуа, бии, җырлый).<br>Мияу *(китап укучы малай рәсемен күрсәтеп):* Малай нишли?<br>Акбай: Читает книгу — китап укый.<br>Мияу: Әйе, китап укый.<br>*(«Китап укый» пиктограммасы белән таныштыру.)*<br>**Аудиоязма тыңлау.** *Аудио (50 нче кисәк)*<br>*(Тәрбияче күрсәтмә рәсемнәрне күрсәтә.)*<br>— Малай китап укый *(пауза).* Малай китап укый *(ир-ат тавышы, тәрбияче рәсемен күрсәтә).*<br>— Кыз китап укый *(пауза).* Кыз китап укый *(хатын-кыз тавышы, тәрбияче рәсемен күрсәтә).*<br>— Куян китап укый *(пауза).* Куян китап укый *(ир-ат тавышы, тәрбияче рәсемен күрсәтә).*<br>— Төлке китап укый *(пауза).* Төлке китап укый *(хатын-кыз тавышы, тәрбияче рәсемен күрсәтә).*<br>*(«Китап» сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.)*<br>**Сүзле уен «Нишли?»**<br>*(Мияу балаларга таратма рәсемнәр өләшә.)*<br>Мияу: Кыз нишли?<br>Коля: Кыз китап укый.<br>Мияу: Куян нишли?<br>Оля: Куян китап укый.<br>Мияу: Төлке нишли?<br>Саша: Төлке китап укый. | Таратма (күрсәтмә) рәсемнәр: куян (аю, песи, эт, төлке, тычкан) сикерә (ашый, эчә, йөгерә, утыра, йоклый, бит юа, чана шуа, бии, җырлый).<br>Күрсәтмә һәм таратма рәсемнәр:<br>Малай китап укый.<br>Кыз китап укый.<br>Куян китап укый.<br>Төлке китап укый.<br>«Укый» пиктограммасы.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 50. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Мияу: Молодцы! В путешествие берём всех ребят. Дорога дальняя. Чтобы в пути не было скучно, будем читать, писать, рисовать.<br>**Дәфтәрдә эш. 16 нчы бирем «Волшебная школа».** | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема<br>Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Март<br>II атна<br>2.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Күңелле сәяхәт.<br><br>*Сүзлек:*<br>рәсем ясыйм<br><br>*Сөйләм үрнәге:*<br>мәктәп | **Уен ситуациясе «Тылсымлы хат».** *Аудио (51 нче кисәк)*<br>Мияу: Перед нами лес. Ребята, смотрите, лесной компьютер, а в компьютере электронное письмо. Это письмо от волшебника. В нём написано, что волшебник рисует — рәсем ясый. Послушайте и повторите за ним. И если мы выполним задание, сможем идти дальше.<br>*(Акбай компьютерны «кабыза».)*<br>— Рәсем ясыйм. Алма ясыйм *(кыска пауза).* Алма ясыйм *(озын пауза, ир-ат тавышы).* — Рәсем ясыйм. Алма ясыйм.<br>— Рәсем ясыйм. Туп ясыйм *(кыска пауза).* Туп ясыйм *(озын пауза, ир-ат тавышы).* — Рәсем ясыйм. Туп ясыйм.<br>— Рәсем ясыйм. Шар ясыйм *(кыска пауза).* Шар ясыйм *(озын пауза, ир-ат тавышы).* — Рәсем ясыйм. Шар ясыйм.<br>— Рәсем ясыйм. Китап ясыйм *(кыска пауза).* Китап ясыйм *(озын пауза, ир-ат тавышы).* — Рәсем ясыйм. Китап ясыйм.<br>**Сүзле уен «Мин рәсем ясыйм».** *(Һавада «алма» рәсемен «ясап» күрсәтә. Балалар, аудионы тыңлап, әйтелгән предметны кул белән һавада «ясап» күрсәтәләр һәм җөмләне кабатлыйлар.)*<br>*Аудио (52 нче кисәк)*<br>Мияу: Ребята, я тоже люблю рисовать. Я рисую яблоко — мин алма ясыйм.<br>— Мин рәсем ясыйм. Мин алма ясыйм *(ир-ат тавышы, озын пауза, балалар рәсемне (һавада) «ясыйлар», җөмләне кабатлыйлар).* — Мин рәсем ясыйм. Мин алма ясыйм.<br>— Мин рәсем ясыйм. Мин туп ясыйм *(ир-ат тавышы, озын пауза, балалар рәсемне (һавада) «ясыйлар», җөмләне кабатлыйлар).* — Мин рәсем ясыйм. Мин туп ясыйм.<br>— Мин рәсем ясыйм. Мин шар ясыйм *(ир-ат тавышы, озын пауза, балалар рәсемне (һавада) «ясыйлар», җөмләне кабатлыйлар).* — Мин рәсем ясыйм. Мин шар ясыйм.<br>— Мин рәсем ясыйм. Мин китап ясыйм *(ир-ат тавышы, озын пауза, балалар рәсемне (һавада) «ясыйлар», җөмләне кабатлыйлар).* — Мин рәсем ясыйм. Мин китап ясыйм.<br>**Сүзле уен «Ватык телефон».** *(Уен «рәсем ясыйм» сүзтезмәсе кулланып үткәрелә.)* | Конвертта хат.<br>Уенчык компьютер.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 51–53. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Рәсем ясау «Мияуга бүләк».** *(Балалар үзләре теләгән рәсемнәрне ясыйлар, әйтәләр):*<br>— Мин рәсем ясыйм. Алма ясыйм.<br>— Мин рәсем ясыйм. Куян (...) ясыйм һ. б.<br>**Үстерешле диалог «Тылсымчыга шалтыратабыз».** *Аудио (53 нче кисәк)*<br>Мияу: Ребята, давайте позвоним лесному волшебнику и скажем, что выполнили его задание. *(Телефоннан.)* Хәерле көн!<br>Тылсымчы: Исәнмесез!<br>Мияу: Хәлләр ничек?<br>Тылсымчы: Әйбәт, син нишлисең?<br>Мияу: Мин рәсем ясыйм.<br>Тылсымчы: Нинди рәсем?<br>Мияу: Алма, туп, шар, китап.<br>Тылсымчы: Әйбәт, килегез мәктәпкә. Приходите в школу.<br>Мияу: Мәктәпкә?<br>Тылсымчы: Әйе, мәктәпкә.<br>Мияу: Рәхмәт! Сау булыгыз!<br>Тылсымчы: Сау булыгыз!<br>**Дәфтәрдә эш. 17 нче бирем «Я рисую».** | |
| **Март**<br>**II атна**<br>**2.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Туган көн.<br><br>*Сүзлек:*<br>җырлыйбыз<br>зур рәхмәт | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Аудиоязма 52. |
| | | **Уен ситуациясе «Мияуда кунакта».**<br>**Тасвирлау аша табышмакларга җавап тап.** *(«Уенчыклар», «Яшелчәләр», «Ашамлыклар», «Кошлар», «Савыт-саба».)*<br>**Уен ситуациясе «Әнинең туган көне», «Кунакларны сыйлыйбыз».**<br>**Җырлы уен «Ак калач».** Аудио (52 нче кисәк)<br>**Үстерешле диалог «Минем бүләгем»** *(әбигә бүләк).* | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Әби, бабай, әти, әни битлекләре.<br>К.В. Закирова. «Балачак аланы» (452, 528 б.).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (239 с.). |
| | | **Уку Г.Тукай «Безнең гаилә» — «Наша семья».**<br>**Уку Мөҗәһит «Мин ничә яшьтә?»**<br>**Уку Дж.Тарджеманов «День рождения дедушки».**<br>**А.Бакиров. Бию музыкасы.**<br>**Уку В.Хәйруллина «Туган көн».** | |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Март**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Күңелле сәяхәт.<br><br>*Сүзлек:*<br>укыйм<br>кем укый | **Уен ситуациясе «Мәктәпкә барам».** *Аудио (54 нче кисәк)*<br>Мияу: Ребята, лесной волшебник приглашает нас в волшебную страну, где говорят только на татарском языке. Возьмите телефон, расскажите друг другу, что вы поёте, танцуете, рисуете, читаете.<br>Коля: Исәнме, Оля!<br>Оля: Хәерле көн, Коля!<br>Коля: Хәлләр ничек?<br>Оля: Әйбәт.<br>Коля: Син нишлисең?<br>Оля: Мин рәсем ясыйм.<br>Коля: Нинди рәсем?<br>Оля: Матур китап. Син нишлисең?<br>Коля: Мин җырлыйм.<br>Оля: Сау бул, Коля!<br>Коля: Сау бул, Оля!<br>*(Шул үрнәктә балалар белән диалог оештырыла.) Аудио (55 нче кисәк)*<br>Мияу: Молодцы, ребята! Мы теперь точно попадём в волшебную страну «Школа» — «Мәктәп».<br>**Сүзле уен «Кем укый?»** *Аудио (56 нчы кисәк).*<br>Акбай: Ребята, мы можем продолжить путь, ведь лесной волшебник пригласил нас в страну, которая называется «Школа» — «Мәктәп». Путешествие продолжается. Но что это? На нашем пути высокая гора, чтобы пройти гору, нужно прочитать пиктограммы. Если мы поймём, что написано, гора даст нам продолжить дорогу.<br>Мияу *(пиктограмма күрсәтеп):* Кем укый?<br>Акбай: Мин укыйм.<br>Акбай укый: Малай рәсем ясый.<br>Мияу *(пиктограмма күрсәтеп):* Кем укый?<br>Оля: Мин укыйм.<br>Оля укый: Куян кишер ашый.<br>Мияу *(пиктограмма күрсәтеп):* Кем укый?<br>Коля: Мин укыйм.<br>Коля укый: Песи сөт эчә.<br>*(Шул үрнәктә һәрбер бала берәр пиктограмманы укып чыга.)*<br>*Пиктограммалар эчтәлеге:*<br>1. Куян кишер ашый.<br>2. Песи сөт эчә. | Телефоннар.<br>Конвертта хат.<br>Пиктограммалар эчтәлеге:<br>Куян кишер ашый.<br>Песи сөт эчә. Аю йоклый. Эт йөгерә.<br>Кыз кул юа. Бабай йоклый. Төлке утыра.<br>Малай рәсем ясый.<br>Үрдәк җырлый. Тычкан бии. Бүре китап укый.<br>Әни бит юа. Әти алма ашый. Кыз чана шуа.<br>Куян сикерә.<br>Дәфтәрдә эш.<br>Аудиоязма 54–57. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 3. Аю йоклый.<br>4. Эт йөгерә.<br>5. Кыз кул юа.<br>6. Бабай йоклый.<br>7. Төлке утыра.<br>8. Малай рәсем ясый.<br>9. Үрдәк җырлый.<br>10. Тычкан бии.<br>11. Бүре китап укый.<br>12. Әни бит юа.<br>13. Әти алма ашый.<br>14. Кыз чана шуа.<br>15. Куян сикерә. *Аудио (57 нче кисәк)*<br>Мияу: Трудное было задание, но мы справились. Дорога свободна. Нас ждут удивительные приключения в следующий раз.<br>**Дәфтәрдә эш. 18 нче бирем «Выполни задание».** | |
| **Март**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Күңелле сәяхәт.<br><br>*Сүзлек:*<br>укыйм<br>кем укый | **Уен «Командир».**<br>Мияу: Ребята, чтобы в дороге вы не устали, сделаем зарядку.<br>1) Өстәлдә «хәрәкәтләр» белдерүче пиктограммалар. Балалар ярымтүгәрәктә. Бер бала, схема-рәсемне алып күрсәтеп: «Сикер» дип, башкаларга команда бирә, балалар сикерә. Уен шулай дәвам итә.<br>2) Балаларга хәрәкәтләрне белдерүче пиктограммалар таратыла, һәм бер-берсенә команда бирәләр.<br>3) Бу уенны терәк рәсемнәрсез дә үткәрергә була. Барлык белгән командалар (сикер, йөгер, утыр, бие, җырла) кулланыла.<br>Бала команданы үти, әйтә: Мин сикерәм (йөгерәм, утырам, биим, җырлыйм).<br>**Аудиоязма тыңлау.**<br>Мияу: Чтобы было веселее идти, послушаем песню. *Аудио (58 нче кисәк)*<br>1) Мин барам, барам, барам,<br>Мәктәпкә барам, барам.<br>Китап, карандаш алам,<br>Мәктәпкә барам, барам.<br>2) Мин барам, барам, барам,<br>Мәктәпкә барам, барам.<br>Китап укыйм, рәсем ясыйм,<br>«Дүрт»ле, «Биш»леләр алам.<br>**Үстерешле уен «Рәсемең турында сөйлә».** *Аудио (59 нчы кисәк)*<br>Мияу: Ребята, вот мы с вами дошли до волшебной страны «Школа» — «Мәктәп». В школу зайдёт тот, кто скажет, что нарисовано на пригласительных билетах. | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Пиктограммалар: сикер, йөгер, утыр, бие, җырла.<br>Чакыру билетлары.<br>Сюжетлы рәсемнәр эчтәлеге: Куян кишер ашый. Песи сөт эчә. Аю йоклый. Эт йөгерә. Кыз кул юа. Бабай йоклый. Төлке утыра. Малай рәсем ясый. Үрдәк җырлый. Тычкан бии. Бүре китап укый. Әни бит юа. Әти алма ашый. Кыз чана шуа. Куян сикерә.<br>Балалар санынча портфель макетлары, карандаш, ручка, китап, пенал, дневник, альбом.<br>Аудиоязма 58–60. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | *(Билетларда сюжетлы рәсемнәр. Һәр бала үзенең рәсеме турында сөйли.)*<br>**Сюжетлы рәсемнәр эчтәлеге:**<br>1. Бу куян. Куян кишер ашый.<br>2. Бу песи. Песи сөт эчә.<br>3. Бу аю. Аю йоклый.<br>4. Бу эт. Эт йөгерә.<br>5. Бу кыз. Кыз кул юа.<br>6. Бу бабай. Бабай йоклый.<br>7. Бу төлке. Төлке утыра.<br>8. Бу малай. Малай рәсем ясый.<br>9. Бу үрдәк. Үрдәк җырлый.<br>10. Бу тычкан. Тычкан бии.<br>11. Бу бүре. Бүре китап укый.<br>12. Бу әни. Әни бит юа.<br>13. Бу әти. Әти алма ашый.<br>14. Бу кыз. Кыз чана шуа.<br>15. Бу куян. Куян сикерә.<br>**Уен ситуациясе «Мәктәптә».** *(Мәктәптә Мияу белән балаларны Акбай каршы ала.) Аудио (60 нчы кисәк)*<br>Акбай: Исәнмесез, балалар!<br>Бергә: Исәнме, Акбай!<br>Акбай: Хәлләр ничек?<br>Бергә: Әйбәт.<br>Акбай: Вы очень быстро прошли препятствия. Я вас поздравляю, возьмите подарки.<br>*(Акбай балаларга портфель макетлары тарата.)*<br>**Уен ситуациясе «Портфельне тутыр».** *(Уку-язу әсбаплары ярдәмендә оешты-рыла. Диалогларның мөмкинлегенә карап, кыска яки үстерешле итеп төзелә.)*<br>Акбай: Портфели пустые. Чтобы наполнить их, надо подойти и спросить веж-ливо. *(Карандаш бир әле.)*<br>а) Оля: Акбай, карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом) бир әле.<br>Акбай: Мә карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом).<br>Оля: Рәхмәт.<br>ә) Коля: Акбай, карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом) бир әле.<br>Акбай: Нинди карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом)?<br>Коля: Кызыл карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом).<br>Акбай: Ничә карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом)?<br>Коля: Бер карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом).<br>Акбай: Мә карандаш (ручка, китап, пенал, дневник, альбом).<br>Коля: Рәхмәт! | |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Март**<br>**III атна**<br>**3.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Урман китапханәсендә.<br><br>*Сүзлек:*<br>китап укый рәсем ясыйм мәктәп | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **Сүзле уен «Мин рәсем ясыйм»** *(үткән лексика буенча).*<br>**Сүзле уен «Портфельдә нәрсә бар?»** *(Балалар портфельдә нәрсәләр барлыгын санап әйтәләр.)*<br>**«Командир» уены.**<br>**Җырлы уен «Музыкаль телефон».** *Аудио (58 нче кисәк)*<br>**Дәфтәрдә эш. 16 нчы бирем «Волшебная школа» (ИКТ-уен).**<br>**Рәсем ясау «Мияуга бүләк».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Анимацион сюжет (45 тема).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (210 с.).<br>К.В. Закирова «Балачак аланы» (205 б.) |
| | | **Анимацион сюжет карау «Урман китапханәсендә»** *(әңгәмә).*<br>**Анимацион сюжетны рольләргә бүлеп уйнау.**<br>**Уку Ш. Маннур «Знай на пять».**<br>**Уку Ш. Галиев «Туган тел».** | |
| **Март**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Мәктәптә.<br><br>*Сүзлек:*<br>бик тәмле | **Сүзле уен «Портфельдә нәрсә бар?»**<br>Мияу: Давайте, вспомним, что мы положили в портфели. Портфельдә нәрсә бар?<br>Балалар: Алма бар?<br>Мияу: Юк.<br>Балалар: Китап бар?<br>Мияу: Әйе, китап бар.<br>*(Уен шул үрнәктә барлык предметлар белән дә дәвам итә.)*<br>**Уен ситуациясе «Ашханәдә».**<br>Өстәлдә ашамлык (аш, ботка, ипи, бәрәңге, сөт, су, сок, чәй, чәкчәк, өчпочмак) рәсемнәре. Мияу повар ролендә. *Аудио (61 нче кисәк)*<br>Мияу: Нәрсә кирәк?<br>Акбай: Аш (ботка, ипи, бәрәңге, сөт, сок, чәй, су, чәкчәк, өчпочмак) кирәк (бир әле).<br>Мияу: Мә аш (ботка, ипи, бәрәңге, сөт, сок, чәй, су, чәкчәк, өчпочмак), аша (эч).<br>Акбай: Рәхмәт.<br>Мияу: Акбай, нишлисең?<br>Акбай: Мин аш (ботка, ипи, бәрәңге, сөт, сок, чәй, су, чәкчәк, өчпочмак) ашыйм (эчәм).<br>Мияу: Аш нинди? | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Балалар санынча картон портфельләр, карандаш, ручка, китап, пенал, дневник, альбом.<br>Ашамлык рәсемнәре: аш, ботка, ипи, бәрәңге, сөт, сок, су, чәй, чәкчәк, өчпочмак.<br>Аудиоязма 61. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Акбай: Аш тәмле. Бик тәмле. Мин аш яратам.<br>*(Шул үрнәктә Мияу белән бала, бала белән бала диалогы үткәрелә.)*<br>**Күңел ачу, җырлау, бию, уеннар.** | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема<br>Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Март<br>IV атна<br>4.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Уку бүлмәсе.<br><br>*Сүзлек:*<br>дәфтәр | **Үстерешле диалог «Уку бүлмәсе белән танышабыз».** *(Уен таратма рәсемнәр ярдәмендә оештырыла.)*<br>Тәрбияче: Мы пришли с вами в школьный класс. Посмотрим, что есть в классе.<br>Мияу: Бу нәрсә?<br>Балалар: Бу өстәл (шкаф, урындык).<br>Мияу: Нинди өстәл (шкаф, урындык)?<br>Балалар: Зур (кечкенә) өстәл (шкаф, урындык).<br>Мияу: Ничә өстәл?<br>Балалар: Бер (1–10 га кадәр) өстәл (шкаф, урындык).<br>Мияу: Өстәлдә нәрсә бар?<br>Балалар: Китап (дәфтәр, карандаш, пенал, ручка, альбом, клей, линейка).<br>*(Диалог шул үрнәктә балалар арасында оештырыла.)*<br>**Үстерешле диалог «Нәрсә, нинди, ничә?»**<br>Фланелеграфта китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр рәсемнәре. *Аудио (62 нче кисәк)*<br>Акбай: Ребята, продолжим путешествие по волшебной стране «Мәктәп».<br>Диалог үрнәкләре:<br>а) Акбай: Бу нәрсә?<br>Балалар: Китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал).<br>Акбай: Нинди китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал)?<br>Балалар: Зур (кечкенә), матур, чиста, ак (кара, кызыл, яшел, сары, зәңгәр) китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал).<br>Акбай: Ничә китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) бар?<br>Балалар: Биш (1–10 га кадәр) китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) бар. *Аудио (63 нче кисәк)*<br>ә) Акбай: Бу нәрсә?<br>Мияу: Белмим.<br>Акбай: Бу дәфтәр. Дәфтәр.<br>Мияу: Дәфтәр. Дәфтәр.<br>Акбай: Нинди дәфтәр?<br>Мияу: Чиста, матур, зур (кечкенә) дәфтәр.<br>Акбай: Ничә дәфтәр?<br>Мияу: Бер (1–10 га кадәр) дәфтәр. | Фланелеграф. Күрсәтмә рәсемнәр: китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр.<br>Ябыштыру өчен балалар санынча рәсемнәр: китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр.<br>Таратма рәсемнәр: төрле төстә, санда (1–10) шкаф, өстәл, урындык.<br>Эш дәфтәре.<br>Балалар санынча клей.<br>Аудиоязма 62–63. |

б) Акбай: Оля, бу нәрсә?
Оля: Дәфтәр. Дәфтәр.
Акбай: Нинди дәфтәр?
Оля: Чиста, матур, яшел (зәңгәр, кызыл, сары) дәфтәр.
в) Мияу: Коля, бу нәрсә?
Коля: Дәфтәр. Дәфтәр.
Мияу: Дәфтәр нинди?
Коля: Дәфтәр зур (кечкенә), ак (сары, яшел, кызыл, зәңгәр, кара).
г) Оля: Коля, бу нәрсә?
Коля: Дәфтәр. Дәфтәр.
Оля: Нинди дәфтәр?
Коля: Зур (кечкенә), матур, чиста, ак (кара, кызыл, яшел, сары, зәңгәр) дәфтәр.
Оля: Ничә дәфтәр?
Коля: Алты (1–10 га кадәр) дәфтәр.
*(«Дәфтәр» сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.)*

**Сүзле уен «Нәрсә кирәк?»**

Тәрбияче: Оля, нәрсә кирәк?
Оля: Дәфтәр кирәк.
Тәрбияче: Мә дәфтәр, ал.
Оля: Рәхмәт!
*(Шул үрнәктә һәр бала тәрбиячедән «эш дәфтәрен» сорап ала.)*

Өстәлдә уку-язу әсбаплары рәсемнәре: китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр. Балалар тәрбиячедән рәсемнәрне сорап алып, дәфтәрләренә ясалган портфельгә ябыштыралар.

Тәрбияче: Оля, нәрсә кирәк?
Оля: Дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк.
Тәрбияче: Нинди дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк?
Оля: Зур (кечкенә), яшел (сары, кызыл, ак, кара, зәңгәр) дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк.
Тәрбияче: Ничә дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк?
Оля: Өч (1–10 га кадәр) дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк.
Тәрбияче: Мә өч (1–10 га кадәр) дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал).
Оля: Рәхмәт!

Һәр бала шул үрнәктә тәрбиячедән уку-язу әсбапларын сорап ала, дәфтәргә ябыштыра.

**Дәфтәрдә эш. 19 нчы бирем «Что в портфеле?»**

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Март**<br>**IV атна**<br>**4.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Күңелле сәяхәт.<br><br>*Сүзлек:*<br>укыйм<br>кем укый? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **Сүзле уен «Кем укый?»**<br>**Пиктограммалар белән эш.**<br>**Уен ситуациясе «Портфельне тутыр!»**<br>**Сүзле уен «Мин кушканны үтә».**<br>**Сүзле уен «Тылсымлы көпшә».** *(И.Н. Мурашковская методикасы буенча.)* *(Балалар көпшәләрдән карап, рәсемне танып исемен әйтә.)*<br>**Үстерешле уен «Рәсемең турында сөйлә»** *(сюжетлы рәсемнәр буенча; үрнәк: аю чана шуа).* | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Р.К. Шәехова. Региональная образовательная программа «Сөенеч» — «Радость познания». |
| | | **«Кызыклы шәкерт» — «Забавный ученик».** *(Ике телдә мультфильм карау. Г.Тукай әсәре буенча.)*<br>**Сәхнәләштерү «Бала белән Күбәләк» Г.Тукай.**<br>**Хәрәкәтле уен «Сыерчык оялары», «Ачкычлар».** | |
| **Апрель**<br>**I атна**<br>**1.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Өстәл театры «Теремкәй».<br><br>*Сүзлек:*<br>кем яши? | **Өстәл театры «Теремкәй» әкияте.** *Аудио (64 нче кисәк) тыңлау, кушылып кабатлау.*<br>Тәрбияче: Сегодня я вам расскажу сказку «Теремок».<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>*(Ишек шакый.)* Теремкәйдә кем яши? Юк, яшәми.<br>Теремкәйгә тычкан килә.<br>Тычкан *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тавыш юк.<br>Тычкан: Юк, яшәми. Мин яшим.<br>Тәрбияче: Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйгә куян килә.<br>Куян *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тычкан: Мин тычкан. Син кем?<br>Куян: Мин куян. Матур куян.<br>Тычкан: Әйдә, кил монда.<br>Куян *(керә):* Мин сикерәм. Әйдәгез сикерәбез.<br>*Балалар белән бергә сикерәләр.* | Өстәл театры атрибутлары: тычкан, куян, бүре, төлке, аю.<br>Аудиоязма 64. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Тәрбияче: Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйгә бүре килә.<br>Бүре *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тычкан: Мин тычкан.<br>Куян: Мин куян.<br>Бергә: Син кем?<br>Бүре: Мин бүре. Мин зур, кара бүре.<br>Бергә: Әйдә, кил монда.<br>Бүре *(керә):* Мин йөгерәм. Әйдәгез йөгерәбез.<br>*(Балалар белән бергә йөгерәләр.)*<br>Тәрбияче: Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши.<br>Теремкәйгә төлке килә.<br>Төлке *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тычкан: Мин тычкан.<br>Куян: Мин куян.<br>Бүре: Мин бүре.<br>Бергә: Син кем?<br>Төлке: Мин төлке. Мин зур, матур төлке.<br>Бергә: Әйдә, кил монда.<br>Төлке *(керә):* Мин биим. Әйдәгез, биибез.<br>Музыка. Балалар белән бергә бииләр.<br>Тәрбияче: Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши.<br>Теремкәйдә төлке яши.<br>Теремкәйгә җырлый-җырлый аю килә.<br>Аю *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тычкан: Мин тычкан.<br>Куян: Мин куян.<br>Бүре: Мин бүре. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Төлке: Мин төлке.<br>Бергә: Син кем?<br>Аю: Мин аю. Мин зур, матур аю.<br>Бергә: Әйдә, кил монда.<br>Аю *(керә):* Мин җырлыйм. Әйдәгез җырлыйбыз.<br>*(Музыка. Балалар белән бергә җырлыйлар.)*<br>Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Тәрбияче: Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә,<br>Теремкәйдә тычкан яши, пи-пи-пи.<br>Теремкәйдә куян яши. Мин куян.<br>Теремкәйдә бүре яши. Мин бүре.<br>Теремкәйдә төлке яши. Мин төлке.<br>Теремкәйдә аю яши. Мин аю.<br>Алар бик дус.<br>*(Күңелле музыка. Биипәр.)* | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема<br>Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Апрель<br>I атна<br>1.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>«Теремкәй» әкиятен сәх-нәләштерү.<br><br>*Сүзлек:*<br>кем яши? | **«Теремкәй» әкиятен сәхнәләштерү.** *(Әкиятне тәрбияче ярдәмендә балалар күрсәтә. Балаларга рольләр бүленеп бирелә (тычкан, куян, бүре төлке, аю), алар битлекләр кияләр һәм «урманга» барып утыралар. Калган балалар, кул-га-кул тотынышып, түгәрәккә басалар, теремкәй ясыйлар. Балалар түгәрәктә әйләнеп йөреп әйтәләр.)*<br>1. Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел *(кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр),*<br>Кечкенә *(чүгәлиләр).*<br>Тук-тук-тук *(уч төпләренә «шакып»)!* Теремкәйдә кем яши?<br>Юк, яшәми *(кулларын җәеп).*<br>Теремкәйгә тычкан килә *(маңгайларына кулларын куеп, тирә-якка карыйлар).*<br>Тычкан битлеге кигән бала, сикереп, образга кереп, теремкәйгә килә.<br>Тычкан *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Балалар: Юк, яшәми. Әйдә кер.<br>Тычкан: Мин яшим *(кереп китә).* | Битлекләр: тычкан, куян, бүре, төлке, аю. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Балалар түгәрәктә әйләнеп йөреп әйтәләр:<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел *(кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр),*<br>Кечкенә *(чүгәлиләр).*<br>Тук-тук-тук *(уч төпләренә «шакып»)!* Теремкәйдә кем яши?<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйгә куян килә *(маңгайларына кулларын куеп, тирә-якка карыйлар).*<br>Куян битлеге кигән бала, сикереп, образга кереп теремкәйгә килә.<br>Куян *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тычкан: Мин тычкан. Син кем?<br>Куян: Мин куян. Матур куян. Мин сикерәм. Әйдәгез сикерәбез.<br>Балалар белән бергә сикерәләр.<br>Тычкан: Куян, әйдә, кил монда.<br>*(Куян кереп китә.)*<br>Балалар түгәрәктә әйләнеп йөреп әйтәләр:<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел *(кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр),*<br>Кечкенә *(чүгәлиләр).*<br>Тук-тук-тук *(уч төпләренә «шакып»)!* Теремкәйдә кем яши?<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйгә бүре килә *(маңгайларына кулларын куеп, тирә-якка карыйлар).*<br>Бүре битлеге кигән бала, сикереп, образга кереп, теремкәйгә килә.<br>Бүре *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тычкан: Мин тычкан.<br>Куян: Мин куян.<br>Бергә: Син кем?<br>Бүре: Мин бүре. Мин зур, кара бүре.<br>Мин йөгерәм. Әйдәгез йөгерәбез.<br>*(Балалар белән бергә йөгерәләр.)*<br>Бергә: Бүре, әйдә, кил монда.<br>Бүре кереп китә.<br>*(Балалар түгәрәктә әйләнеп йөреп әйтәләр.)*<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел *(кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр),*<br>Кечкенә *(чүгәлиләр).*<br>Тук-тук-тук *(уч төпләренә «шакып»)!* Теремкәйдә кем яши?<br>Теремкәйдә тычкан яши. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши.<br>Теремкәйгә төлке килә *(маңгайларына кулларын куеп, тирә-якка карыйлар).*<br>Төлке битлеге кигән бала, сикереп, образга кереп, теремкәйгә килә.<br>Төлке *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тычкан: Мин тычкан.<br>Куян: Мин куян.<br>Бүре: Мин бүре.<br>Бергә: Син кем?<br>Төлке: Мин төлке. Мин зур, матур төлке. Мин биим. Әйдәгез биибез.<br>*Музыка. Балалар белән бергә бииләр.*<br>Бергә: Төлке, әйдә, кил монда.<br>*(Төлке кереп китә.)*<br>Балалар түгәрәктә әйләнеп йөреп әйтәләр:<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел *(кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр),*<br>Кечкенә *(чүгәлиләр).*<br>Тук-тук-тук *(уч төпләренә «шакып»)!* Теремкәйдә кем яши?<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши.<br>Теремкәйдә аю яши.<br>Теремкәйгә аю килә *(маңгайларына кулларын куеп, тирә-якка карыйлар).*<br>Аю битлеге кигән бала, сикереп, образга кереп, теремкәйгә килә.<br>Аю *(ишек шакый):* Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>Тычкан: Мин тычкан.<br>Куян: Мин куян.<br>Бүре: Мин бүре.<br>Төлке: Мин төлке.<br>Бергә: Син кем?<br>Аю: Мин аю. Мин зур, матур аю. Мин җырлыйм. Әйдәгез җырлыйбыз.<br>*Музыка. Балалар белән бергә җырлыйлар.*<br>Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Тәрбияче: Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә,<br>Теремкәйдә тычкан яши, пи-пи-пи.<br>Теремкәйдә куян яши. Мин куян.<br>Теремкәйдә бүре яши. Мин бүре.<br>Теремкәйдә төлке яши. Мин төлке.<br>Теремкәйдә аю яши. Мин аю.<br>Алар бик дус.<br>*(Күңелле музыка. Биилләр.)* | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема**<br>**Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Апрель**<br>**I атна**<br>**1.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>«Теремкәй».<br><br>*Сүзлек:*<br>кем яши? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Аудио №71. |
| | | **«Теремкәй» әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек.**<br>**Сүзле уен «Ягымлы сүзләр дөньясына сәяхәт» (УМК буенча).**<br>**Сүзле уен «Кем нинди өйдә яши?»** *(Схема буенча бала һәрбер уенчык-җәнлекне үз өенә урнаштыра.)* | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | |
| | | **Г.Тукай әсәрләре буенча шигъри бәйге.** *(Рус һәм татар телләрендә.)*<br>**Рәсемнәр күргәзмәсе** *(Г.Тукай әсәрләре буенча).* | |
| **Апрель**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Өстәл театры «Кем нәрсә ярата?»<br><br>*Сүзлек:*<br>кем нәрсә ярата?<br>яратам<br>хәерле көн | **Өстәл театры «Кем нәрсә ярата?»** *(Аудио 65 нче кисәк)*<br>Тәрбияче: Я вам расскажу сказку «Кто что любит» — «Кем нәрсә ярата?», а вы мне помогите.<br>Персонажлар: Эт, песи, әтәч, кәҗә.<br>Күренеш: Өй макеты. Бу өйдә әтәч, эт, песи, кәҗә яшиләр. Ишегалдында яшел чирәм үсә. Өйдән ерак түгел эт оясы. Иртә. Кош сайраган тавышлар ишетелә. Киртәгә әтәч сикереп менә. Канат кагып кычкыра.<br>Әтәч: Кикри-күк, кикри-күк.<br>Әтәч киртәдән сикереп төшә дә чирәм чүпли башлый: Ко-ко-ко.<br>Өйдән әкрен генә, ялкау атлап, песи чыга, киерелә: Мияу-мияу-мияу.<br>Песи әтәчкә карап: Хәерле көн, әтәч.<br>Әтәч: Хәерле көн, песи.<br>Песи: Хәлләр ничек, әтәч?<br>Әтәч: Әйбәт. Рәхмәт! Ә синең хәлләрең ничек?<br>*Шулвакыт, йөгерә-йөгерә, эт чабып чыга.* | Өй макеты.<br>Өстәл театры атрибутлары: эт, песи, әтәч, кәҗә.<br>Аудиоязма 65. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Эт: Һау-һау-һау! Исәнме, әтәч! Исәнме, песи!<br>Әтәч белән песи: Исәнме, эт!<br>Эт: Кәҗә кая?<br>Әтәч белән песи: Әнә кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.<br>Эт: Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>Песи: Мин сөт яратам. Сөт тәмле. Әтәч, син нәрсә яратасың?<br>Әтәч: Мин ботка яратам. Ботка тәмле.<br>*Кәҗә килә, кәрзиндә кәбестә, сөт, ипи, ботка.*<br>Кәҗә: Исәнмесез! Хәерле көн! Хәлләр ничек?<br>Бергә: Әйбәт.<br>Кәҗә: Мин кәбестә ашыйм. Кәбестә бик тәмле. Акбай, мә кәбестә, аша. Кәбестә тәмле.<br>Акбай: Юк, мин ипи яратам. Син кәбестә аша. Ипи кирәк.<br>Кәҗә: Мә ипи, аша.<br>Акбай: Рәхмәт! Ипи тәмле.<br>Песи: Мин сөт яратам. Сөт юк.<br>Кәҗә: Сөт бар. Песи, кил монда. Сөт ал, эч.<br>Песи сөт эчә: Мин сөт эчәм. Сөт тәмле. Әтәч, кил монда, сөт эч.<br>Әтәч: Юк, мин сөт яратмыйм. Мин ботка яратам. Ботка юк.<br>Кәҗә: Ботка бар, кәрзиндә. Әтәч, кил монда. Мә ботка, аша.<br>Әтәч: Зур рәхмәт. Ботка бик тәмле. Мә, кәҗә, ботка аша.<br>Кәҗә: Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.<br>Әтәч: Юк, ботка тәмле.<br>Песи: Юк, сөт тәмле.<br>Эт: Юк, ипи тәмле.<br>*Кыз, бәхәсләшкәннәрен ишетеп, алар янына килә.*<br>Кыз: Ипи тәмле, сөт тәмле, ботка тәмле, кәбестә тәмле. Мин ипи, ботка, кәбестә яратам.<br>*Бергә җырлап, биигиләр.*<br>Ипи тәмле,<br>Сөт тәмле,<br>Ботка тәмле,<br>Кәбестә тәмле. | |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Апрель**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>«Кем нәрсә ярата?» әкиятен сәхнәләштерү.<br><br>*Сүзлек:*<br>кем нәрсә<br>ярата?<br>яратам<br>хәерле көн | **«Кем нәрсә ярата?» әкиятен сәхнәләштерү.** *(Әкиятне тәрбияче ярдәмендә балалар күрсәтә. Балаларга рольләр бүленеп бирелә (әтәч, эт, песи, кәҗә), алар битлекләр киядәр. Персонажлар: Эт, песи, әтәч, кәҗә. Күренеш: Өй макеты. Бу өйдә әтәч, эт, песи, кәҗә яшиләр. Ишегалдында яшел чирәм үсә. Өйдән ерак түгел эт оясы. Иртә. Кош сайраган тавышлар ишетелә. Киртәгә әтәч сикереп менә. Канат кагып кычкыра.)*<br>Әтәч: Кикри-күк, кикри-күк.<br>Әтәч киртәдән сикереп төшә дә чирәм чүпли башлый: Ко-ко-ко.<br>Өйдән әкрен генә, ялкау атлап, песи чыга, киерелә: Мияу-мияу-мияу.<br>Песи, әтәчкә карап: Хәерле көн, әтәч!<br>Әтәч: Хәерле көн, песи!<br>Песи: Хәлләр ничек, әтәч?<br>Әтәч: Әйбәт. Рәхмәт. Ә синең хәлләрең ничек? *(Шулвакыт йөгерә-йөгерә эт чабып чыга.)*<br>Эт: Һау-һау-һау! Исәнме, әтәч! Исәнме, песи!<br>Әтәч белән песи: Исәнме, эт!<br>Эт: Кәҗә кая?<br>Әтәч белән песи: Әнә кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.<br>Эт: Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>Песи: Мин сөт яратам. Сөт тәмле. Әтәч, син нәрсә яратасың?<br>Әтәч: Мин ботка яратам. Ботка тәмле.<br>*Кәҗә килә, кәрзиндә кәбестә, сөт, ипи, ботка.*<br>Кәҗә: Исәнмесез! Хәерле көн! Хәлләр ничек?<br>Бергә: Әйбәт.<br>Кәҗә: Мин кәбестә ашыйм. Кәбестә бик тәмле. Акбай, мә кәбестә аша, тәмле.<br>Акбай: Юк, мин ипи яратам. Син кәбестә аша. Ипи кирәк.<br>Кәҗә: Мә ипи, аша.<br>Акбай: Рәхмәт! Ипи тәмле.<br>Песи: Мин сөт яратам. Сөт юк.<br>Кәҗә: Сөт бар. Песи, кил монда. Сөт ал, эч.<br>Песи сөт эчә: Мин сөт эчәм. Сөт тәмле. Әтәч, кил монда, сөт эч.<br>Әтәч: Юк, мин сөт яратмыйм. Мин ботка яратам. Ботка юк.<br>Кәҗә: Ботка бар, кәрзиндә. Әтәч, кил монда. Мә ботка, аша.<br>Әтәч: Зур рәхмәт! Ботка бик тәмле. Мә, кәҗә, ботка аша.<br>Кәҗә: Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.<br>Әтәч: Юк, ботка тәмле.<br>Песи: Юк, сөт тәмле. | Өй макеты.<br>Битлекләр: эт, песи, әтәч, кәҗә.<br>Аудиоязма 66. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Кыз, бәхәсләшкәннәрен ишетеп, алар янына килә.<br>Кыз: Ипи тәмле, сөт тәмле, ботка тәмле, кәбестә тәмле. Мин ипи, ботка, кәбестә яратам. *(Бергә җырлап, бииләр. Аудио (66 нчы кисәк)*<br>Ипи тәмле,<br>Сөт тәмле,<br>Ботка тәмле,<br>Кәбестә тәмле. | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема<br>Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Апрель<br>II атна<br>2.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Уйныйбыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>Кем нәрсә ярата?<br>яратам<br>хәерле көн | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **«Кем нәрсә ярата?» әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек.**<br>**Дидактик уен «Бу нәрсә?»**<br>**«Хатаны төзәт»** *(һәрбер балада — битлекләр).*<br>**Хәрәкәтле уен «Үзеңә пар тап».** *(Тәрбияче командасы буенча балалар йөгерәләр, музыка туктагач, битлекләр буенча үзенә туры килгән парны табалар.)*<br>**«Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча уеннар, диалогларны, җырларны кабатлау.** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | Аудиоязма 72.<br>К.В. Закирова «Балачак аланы» (520 б.). |
| | | **Өстәл театры «Кем нәрсә ярата?»**<br>**Уку Г. Зәйнашева «Әбиемне яратам».**<br>**Аз хәрәкәтле уен «Ни өчен?»** *(Мин кыяр яратам, чөнки ул тәмле. Ә син нәрсә яратасың?)* | |
| **Апрель<br>III атна<br>3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Белем иленә сәяхәт.<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Зур матур китап. Һәр битендә темалар буенча сюжетлы һәм аерым рәсемнәр.** *Аудио (67 нче кисәк)*<br>— Какая красивая книга. Ребята, эта книга волшебная. На каждой её страничке таится секрет, волшебство. Давайте посмотрим вместе, какая тайна спрятана в этой волшебной книге.<br>*Тәрбияче китапның беренче битен ача. Беренче биттә «Гаилә», «Ашамлыклар» темасына караган рәсемнәр.*<br>**Үстерешле уен «Бу кем? Нәрсә? Нинди? Нишли?»**<br>а) Балаларга рольләр бүленеп бирелә, алар, битлекләр киеп, үзләре турында рәсемнәргә һәм муляжларга карап сөйлиләр.<br>Әни: Мин әни. Мин зур, әйбәт (ипигә күрсәтеп яисә ипине алып). Мин ипи яратам. Ипи тәмле.<br>Әти: Мин әти. Мин зур, матур. Мин аш яратам. Аш тәмле.<br>*Шул үрнәктә һәр бала сөйли.* | Балалар санынча яшелчә, җиләк-җимеш рәсемнәре.<br>Уенчыклар, савыт-саба, йорт җиһазлары.<br>Аудиоязма 67–69.<br>Эш дәфтәре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ә) Һәр бала, рәсемнәргә карап, тәрбияче (Акбай, Мияу) үрнәгендә үзе теләгән гаилә әгъзасы, ашамлык турында кыска хикәя төзеп сөйли.<br>*Аудио (68 нче кисәк)*<br>Акбай: Бу әни. Әни матур, әйбәт, зур. Бу ипи. Әни ипи ашый. Ипи тәмле. Әни ипи ярата.<br>Мияу: Бу әти. Әти зур, матур, әйбәт. Бу сөт. Әти сөт эчә. Сөт тәмле. Әти сөт ярата.<br>**Уен ситуациясе. Үстерешле диалог «Әйдәгез танышабыз».**<br>*(Икенче биттә «Җәнлекләр», «Йорт кошлары» темасына караган рәсемнәр.)*<br>*Балалар рольләргә керәләр, үзара булган лексиканы кулланып, диалог төзеп сөйлиләр. «Нишлисең?» соравына белгән фигыльләрне кулланалар.*<br>Җәнлекләр, кошлар очрашалар.<br>Төлке белән керпе.<br>а) Төлке *(биеп торган керпе янына килә):* Исәнме, керпе!<br>Керпе: Исәнме, төлке! Хәлләр ничек?<br>Төлке: Әйбәт. Керпе, син нишлисең?<br>Керпе: Мин биим. Төлке, кил, бие. *(Төлкене биергә чакыра. Төлке бии.)*<br>Төлке: Мин биим *(икәү биилəр, бии-бии китәләр).*<br>ә) Куян белән тычкан.<br>Куян: Хәерле көн, тычкан!<br>Тычкан: Хәерле көн, куян!<br>Куян: Тычкан, мин зур. Син нинди?<br>Тычкан: Ә мин кечкенә. Куян, син нишлисең?<br>Куян: Мин сикерәм *(скакалкадан сикерә).* Син нишлисең?<br>Тычкан: Мин җырлыйм *(җырлый)?* Куян, кил, җырла *(куянны җырларга чакыра). Икәү җырлый-җырлый китәләр. Аудио (69 нчы кисәк)*<br>Мин куян, мин куян,<br>Зур куян, матур куян.<br>Мин тычкан, мин тычкан,<br>Кечкенә, матур тычкан.<br>*Диалог шул үрнәктә башка балалар белән дәвам ителә.*<br>**Уен «Компот, салат ясыйбыз».**<br>*(Китапның өченче бите ачыла. «Яшелчәләр», «Җиләк-җимешләр».)*<br>Нәрсә кирәк? Бел!<br>Балалар компот һәм салат өчен кирәкле яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне әйтәләр. Рәсемдә кәстрүл һәм пыяла савыт (надрез белән). Балалар яшелчә, җиләк-җимеш исемнәрен әйтәләр, кирәкле урынга урнаштыра баралар.<br>*Бу эшне дәфтәрдә эш итеп алып та була.* | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Дәфтәрдә эш. 20 нче бирем «Помоге маме».**<br>**Ситуатив күнегү «Уенчыклар качканнар». («Нәрсә юк?» яисә «Дөрес урнаштыр».)**<br>(Китапның дүртенче битендә «Уенчык», «Савыт-саба», «Йорт җиһазлары» темалары буенча рәсемнәр.)<br>Тәрбияченең өстәлендә уенчыклар, савыт-саба, йорт җиһазлары төрлечә урнаштырылган. Балалар дөрес итеп классификацияләргә тиеш. | |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Апрель**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>«Могҗизалар кыры».<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Үстерешле уен «Бу кем? Нәрсә? Нинди? Нишли?»**<br>**Уен «Компот, салат ясыйбыз». Сүзле уен «Светофор төсләре».**<br>**Хәрәкәтле уен «Светофор»** *(уенның эчтәлеге кушымтада).*<br>**Хәрәкәтле уен «Төсле самолётлар»** *(мәйданчыкка төрле төстәге боҗралар урнаштырыла, һәрбер бала кулында төсле туплар, тәрбияче командасы буенча балалар очалар, йөгерәләр һәм үз-үзенә туры килгән төс — аэродромга очып төшәләр).*<br>**«Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча уеннар** *(тәрбияче теләге буенча).*<br>**Сүзле уен «Белмәмешкә светофорның төсләрен дөрес урнаштырырга ярдәм ит».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br><br>**Сүзле-музыкаль уен «Оркестр».** *(Үрнәк: мин уйныйм, уйныйм, уйныйм, мин гитарада уйныйм... һәрбер бала үзенә музыкаль инструмент сайлый һәм җырлый).*<br>**Мультфильм карау «Эш беткәч, уйнарга ярый» Г.Тукай.**<br>**Сәхнәләштерү «Эш беткәч, уйнарга ярый» Г.Тукай.** | |
| **Апрель**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>«Могҗизалар кыры». | **Уен ситуациясе «Серле хат».**<br>Тәрбияче: Ребята, нам прислали электронное письмо. Письмо от Королевы выпускного бала. Давайте послушаем. *Аудио (70 нче кисәк)*<br>«Дорогие ребята! Я Вас приглашаю на выпускной бал, который состоится в моём королевстве «Знаний». Но для этого вы должны выполнить все мои задания. Мои задания в этом волшебном сундучке. Если все задания выполните успешно, вы непременно попадёте в моё королевство, где говорят на красивом татарском языке. Желаю Вам удачи, и с нетерпением жду Вас у себя». | «Могҗизалар кыры» уенына кирәкле җиһазлар, биремнәр. Аудиоязма 70–71. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *Сүзлек:* Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | *Өстәлдә һәр тема буенча төрле типтагы биремнәр (сюжетлы рәсемнәр, пиктограммалар) бирелгән конвертлар.* *Бала өстәлдән бер конвертны ала, тәрбиячегә бирә. Тәрбияче биремне укый, бала үти. Биремнәрне өйрәнгән лексиканы, материалны кулланып, ковролинда, магнитлы тактада, интерактив тактада, дәфтәрдә дә әзерләргә була. Биремнәрне шулай күмәк, аерым-аерым командаларга бүленеп үтәргә була. Биремнәр арасында музыкаль тәнәфес. (Аудио (71 нче кисәк)* Ребята, молодцы! Вы выполнили все мои задания. Добро пожаловать в моё королевство «Знаний», где говорят на красивом татарском языке. Желаю вам удачи! | |
| **Апрель IV атна 4.2** Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:** «Без инде хәзер зурлар — мәктәпкә илтә юллар». *Сүзлек:* Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Уен ситуациясе «Кая барасың?»** *(Мәктәп, кафе, цирк һ. б.)* **Уен-диалог «Бу нәрсә? Нинди? Ничә? Нишли?»** **Хәрәкәтле уен «Урман дусларыбызга мәктәпкә юлны табарга ярдәм ит».** *(Үрнәк: Куян, кил монда, сикер. Куян, син нишлисең? Мин сикерәм, йөгерәм... төлке җырлый, бүре бии... конструкцияләрен ныгыту.)* **Үткәннәрне кабатлау. «Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча уеннар.** **Уен ситуациясе «Телефоннан сөйләшү»** (диалогны сан, сыйфат, күләм берәмлеге кертеп баетырга була). | Маскалар, таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр. |
| **Үткәрү вакыты** | **Тема Сүзлек** | **Эш төрләре** | **Җиһазлау** |
| **Апрель IV атна 4.3** (режим вакыты) | **Тема:** «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар». | **Режим вакытында уен эшчәнлеге** (Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү.** *(Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?)* **Хәрәкәтле уен «Буяулар».** **Музыкаль-хәрәкәтле уен «Кызыклы паровоз».** *(Паровоз бара, бара, команда буенча туктый. Тукталышлар: рәсем тукталышы (рәсем ясыйлар), музыкаль тукталыш (җырлыйлар), бию тукталышы (бииләр), спорт тукталышы (сикерәләр, йөгерәләр.)* **Игра-забава «Оживи рисунок».** *(Необходимо дорисовать недостающий элемент и рассказать про получившийся предмет.)* | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *Сүзлек:* Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Анимацион сюжет карау «Урман китапханәсендә».**<br>**Сюжетны рольләргә бүлеп уйнау.**<br>**Татар халык уеннары «Аксак төлке», «Тимербай».** | Анимацион сюжет (45 тема). |
| **Май**<br>**I атна**<br>**1.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:** Уйныйбыз да, җырлыйбыз да.<br><br>*Сүзлек:* Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Сүзле-хәрәкәтле уен «Мин әйтәм – син эшлә».** *(Уйна, уйный, уйныйм. Җырла, җырлыйм, җырлый. Мин матур җырлыйм. Төлке матур җырлый.)*<br>**Музыкаль дидактик уен «Бу нинди җыр?»** *(«Бар матур бакча», «Бар матур төлке...»)*<br>**Сүзле уен «Яшь артистлар».** *(Музыка инструментлары белән.)*<br>**Музыкаль уен «Зур концерт».** *(Проект темалары буенча.)* | Хәрәкәт белдерүче пиктограммалар, төрле уенчыклар.<br>«Минем өем», «Уйный-уйный үсәбез», «Без инде хәзер зурлар — мәктәпкә илтә юллар» проектлары буенча лексика. |
| **Май**<br>**I атна**<br>**1.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:** Тыңлагыз, тыңлагыз! Балалар сөйләшә.<br><br>*Сүзлек*[1] | **Үстерешле уен «Уенчык (куян, аю, бүре, төлке...) турында сөйлә»**<br>**Сүзле уен «Портфельдә нәрсә бар?»**<br>**Дидактик уен «Кем, нәрсә юк?» «Бу нәрсә?»**<br>**Үстерешле уен.** *(Син кем? нинди? — команда — нишли? нишлисең?)*<br>**«Командир» уены. Диалог «Син нишлисең?»** | Хәрәкәт белдерүче пиктограммалар, төрле уенчыклар, савыт-саба, киемнәр, яшелчәләр, уку кирәк-яраклары. |

[1] *Сүзлек:* Өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмәләрне сөйләмдә активлаштыру, үзлектән җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү. Ягымлы сүзләр — исәнмесез, сау булыгыз, зур рәхмәт, бик тәмле. Нишли? Уйный, бии, сикерә, йөгерә, ашый, җырлый, рәсем ясый, китап укый. Нишлисең? Уйныйм, биим, йөгерәм, ашыйм, җырлыйм, рәсем ясыйм, китап укыйм.

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Май**<br>**I атна**<br>**1.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Мәктәпкә барабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>Кабатлау. | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | Сюжетлы рәсемнәр. |
| | | **«Минем өем», «Уйный-уйный үсәбез», «Без инде хәзер зурлар — мәктәпкә илтә юллар» проектларын кабатлау буенча уен эшчәнлекләре.** *(Дәфтәрдә эш №8, №12.)*<br>**Үстерешле диалог: «Нишли?, Нишлисең?»**<br>**Сюжетлы-рольле уен «Уенчык кибетендә».**<br>**«Дөрес әйт!», «Нәрсә зур, нәрсә кечкенә?», «Әйе — юк», «Сана» дидактик уеннары.** *(Темага кагылышлы уенчыклар уртага куела, балалар җырны тыңлап әйләнәләр.)*<br>**Сүзле уен «Мин мәктәпкә үзем белән нәрсә алам?»** *(Үрнәк: өстәл – юк, песи – юк, китап – әйе... Телевизор – юк, карават – юк, дәфтәр – әйе...)*<br>**Үстерешле уен «Мин кем турында сөйлим?»** *(«Гаилә», «Йорт кошлары», «Җәнлекләр» темалары лексикасын ныгыту.)*<br>**«Весёлый танец народов Поволжья».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (143 с.). |
| | | **Җырлы-биюле уен «Карусель»** *(рольләргә бүленеп).*<br>**«Стоит в поле теремок»** *(лего).*<br>**Уку Р.Валеева «Самая красивая страна».**<br>**Уку Р.Валеева. «Иң матур ил».** | |
| **Май**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Мәктәпкә барабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Уен «Командир».**<br>**Үстерешле уен «Рәсемең турында сөйлә».**<br>**Уен ситуациясе «Мәктәпкә барам».**<br>**Уен ситуациясе «Мәктәптә».**<br>**Уен ситуациясе «Портфельне тутыр».** *Аудио (54–56 нчы кисәкләр)*<br>**Сүзле уен «Кем укый?»**<br>**Үстерешле диалог «Бу нәрсә?» «Нишли?» «Нишлисең?»**<br>**Пиктограммалар уку.** *(Укый, укыйм, сикерә, сикерәм, рәсем ясый, рәсем ясыйм, җырлый, җырлыйм, бии, биим.)* | Хәрәкәт белдерүче пиктограммалар, төрле уенчыклар.<br>«Минем өем», «Уйный-уйный үсәбез», «Без инде хәзер зурлар — мәктәпкә илтә юллар» проектлары буенча лексика. |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Май**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Мәктәпкә барабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Проектлар буенча уен ситуацияләре: «Чынаяклар, киемнәр, уенчыклар югалган», Серле хат», «Мәктәпкә барабыз», «Портфельне тутыр».**<br>**Сүзле уен «Портфельдә нәрсә бар? — иптәшеңә сөйлә».**<br>**Үстерешле диалог «Нишли?», «Син кем? Син нишлисең?»** | Хәрәкәт белдерүче пиктограммалар, төрле уенчыклар.<br>«Минем өем», «Уй-ный-уйный үсәбез», «Без инде хәзер зур-лар — мәктәпкә илтә юллар» проектлары буенча лексика. |
| **Май**<br>**II атна**<br>**2.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Мәктәпкә барабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән те-малар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **Уен ситуациясе «Кая барасың?»** *(Мәктәп, кафе, цирк һ. б.)*<br>**Уен-диалог «Бу нәрсә? Нинди? Ничә? Нишли?»**<br>**Хәрәкәтле уен «Хәйләкәр төлке».**<br>**Хәрәкәтле уен «Урман дусларыбызга мәктәпкә юлны табарга ярдәм ит».** *(Үрнәк: Куян, кил монда, сикер. Куян, син нишлисең? Мин сикерәм, йөгерәм... төлке җырлый, бүре бии... конструкцияләрен ныгыту.)*<br>**Уен ситуациясе «Телефоннан сөйләшү».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (241, 534 с.). |
| | | **Уку М.Хәсәнов «Сара мәктәпкә бара».**<br>**Уку Р.Миннуллин «Первый класс».**<br>**Театральләштерелгән эшчәнлек «Урман мәктәбе».** *(Урман җәнлекләре, мәк-тәп әсбаплары, ашамлыклар һ. б. исемнәрен кабатлау.)*<br>**Игра «Найди знакомые слова»** *(яраткан әкиятләрне карау).* | |
| **Май**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Сау бул, бакча! Исәнме, мәктәп. | **Үстерешле диалог «Корреспондент».**<br>**Концерт-уен «Яшь артистлар»** *(җырлар җырлау, бию, сөйләү).*<br>**Музыкаль уен «Музыка коралларында уйныйм»** *(уйныйм, җырлыйм).*<br>**Әйлән-бәйлән уены (Кем, кем мәктәпкә бара? Нәрсә, нәрсә ул ала?)** | Хәрәкәт белдерүче пиктограммалар (җырлый).<br>Әйлән-бәйлән уеннары өчен атрибутлар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Май**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Сау булыгыз, уенчыклар! Сау булыгыз, апалар!<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Түгәрәк уены «Сау булыгыз, уенчыклар, сау булыгыз, апалар».**<br>**Уен ситуациясе «Мәктәпкә барабыз, «дүрт»ле, «биш»ле алабыз»** *(рольләргә бүленеп).*<br>**Уен ситуациясе «Сау булыгыз, уенчыклар!»**<br>**Сүзле уен «Портфельдә нәрсә артык?»**<br>**Сюжетлы рәсемнәр белән эшләү «Кем укый?» «Кем рәсем ясый?»...** | Пиктограммалар, сюжетлы рәсемнәр. |
| **Май**<br>**III атна**<br>**3.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар.<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | |
| | | **Хәрәкәтле уен «Буяулар»** *(битлекләр киеп).*<br>**Музыкаль-хәрәкәтле уен «Кызыклы паровоз»** *(паровоз бара, бара, командa буенча туктый. Тукталышлар: рәсем тукталышы (рәсем ясыйлар), музыкаль тукталыш (җырлыйлар), бию тукталышы (бииләр), спорт тукталышы (сикерәләр, йөгерәләр).*<br>**Сюжетлы-рольле уен «Мәктәп».** | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (242 с.).<br>К.В. Закирова «Балачак аланы» (533 б.). |
| | | **Сабантуй бәйрәме** *(күңел ачу һәм уеннар).*<br>**Уку Р.Миңнулин «Бакча белән хушлашу».**<br>**Уку Х.Бадиги «Здравствуй, сентябрь!»** | |
| **Май**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Күңелле уеннар.<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Хәрәкәтле уеннар «Тимербай»** *(татар халык уены),* **«Мы весёлые ребята»** *(рус халык уены),* **«Уральский мяч»** *(башкорт халык уены),* **«Заяц, заяц, ты где?»** *(мари халык уены).*<br>**Уен ситуацияләре «Кем килде?» «Кемгә нәрсә?» «Кем нәрсә ярата?» «Нәрсә юк?» «Кем нишли?»**<br>**Түгәрәк уеннары «Карусель», «Портфелеңдә нәрсә бар?»** | Р.К. Шаехова. Региональная образовательная программа «Сөенеч» — «Радость познания» (140–141 с.). |

| Үткәрү вакыты | Тема<br>Сүзлек | Эш төрләре | Җиһазлау |
|---|---|---|---|
| **Май<br>IV атна<br>4.2**<br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>Уйныйбыз да уйный-быз.<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **«Капчык киеп йөгерү», «Көянтә белән су ташу», «Чүлмәк вату», «Кашыкка йомырка куеп йөгерү», «Катык»** — *милли-ярыш уеннары.*<br>**Сюжетлы-рольле уеннар «Без Сабантуйда», «Кафеда», «Кунакта», «Әбидә».**<br>**Сәхнәләштереп уйнау Ш.Галиев «Сабантуй батыры».** | Р.К. Шаехова. Региональная образовательная программа «Сөенеч» — «Радость познания» (140 с.).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (526–527 с.). |
| **Май<br>IV атна<br>4.3**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Без әкият яратабыз.<br><br>*Сүзлек:*<br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла. | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | К.В. Закирова «На поляне детства» (544 с.). |
| | | **В.Сутеев «Яблоко»** *(драматизация).*<br>**Татар халык әкияте «Өч кыз»** *(курчак театры).*<br>**Татар халык әкияте «Чуар тавык** *(өстәл театры).*<br>**Рус халык әкияте «Теремкәй** *(бармак театры).*<br>**Рус халык әкияте «Казлар-аккошлар»** *(лего театры).* | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | К.В. Закирова «На поляне детства» (126, 205 с.).<br>К.В. Закирова «Балачак аланы» (532–533 б.) |
| | | **Уку Н. Дәүли «Минем дустым — әлифба».**<br>**Уку Б.Рәхмәт «Мәктәпкә».**<br>**Уку А.Исхак «Как Сюмбюля училась считать».**<br>**А.Алиш «Огненное яичко»** *(драматизация).* | |

# ЭЧТӘЛЕК


Пояснительная записка. Планирование образовательного процесса в режимных моментах по обучению татарскому языку ............ 3

**Уртанчылар төркеме.** «Минем өем» проекты буенча тематик план ............ 4
«Минем өем» проекты (4-5 яшьлек балалар өчен) ............ 6

**Зурлар төркеме.** «Уйный-уйный үсәбез» проекты буенча тематик план ............ 58
«Уйный-уйный үсәбез» проекты (5-6 яшьлек балалар өчен) ............ 60

**Мәктәпкә әзерлек төркеме.** «Без инде хәзер зурлар — мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча тематик план ............ 90
«Без инде хәзер зурлар — мәктәпкә илтә юллар» проекты (5-6 яшьлек балалар өчен) ............ 92